وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№2 (235). ФЕВРАЛЬ - 2015 / РАБИГЫЛАХЫР-ҖӘМӘДИӘЛӘҮВӘЛ - 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

Газетада Аллаһы тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanудан сакланыгыз!



## Татарстан мөфтияте татар шәмаилләре конкурсын игълан итә

9 бит



## Без бер-беребезне кайгыртып яшәргә тиеш

2 бит



## Хатыны җәннәтле булсын өчен ирнен бер сүзе житә

11 бит



## Чын ирләр чын аналардан туа

10 бит

# БЕЗ БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ КАЙГЫРТЫП ЯШӘРГӘ ТИЕШ

## ДУМ РТ делегациясе Төркиягә сәфәр кылды

***Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте делегациясе Төркиягә эшлекле сәфәр кылды. Делегация составына мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров, ТР МДН аппараты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, нәзарәтнең халыкара мөнәсәбәтләр бүлеге җитәкчесе Хәйдәр Камалетдинов керде. Шулай ук Татарстан Президентының дини берләшмәләр белән багланышлар идарәсе башлыгы Илнур Гатауллин, Россия мөселман эшкуарлар ассоциациясе җитәкчесе Марат Кабаев та мөфти белән бергә сәфәр кылды.***



Татарстан мөфтиятенең чит илгә сәфәре үзара хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре кору һәм Төркиядәге дини эшләр белән танышу максатыннан оештырылды.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Төркиянең Дин эшләре идарәсе җитәкчесе Мехмет Гөрмез белән очрашты. Дин әһелләре фән, мәгариф, нәшрият өлкәсендә үзара хезмәттәшлек итү хакында сөйләштеләр. Төгәлрәк әйткәндә, сүз рухи мирасны өйрәнүгә кагылышлы уртак проектлар эшләү, Коръәннең "Казан басмасы"н чыгару турында барды. Изге китапның яңа нөсхәсе ТР МДН соравы буенча танылган каллиграф Мөхсин Демирел тарафыннан нәсх стилендә эшләнде. Очрашу нәтиҗәсендә Иске китапларны һәм кульязмаларны өйрәнү үзәген булдырырга кирәк дигән фикергә киленде. Мәгълүм булганча, бүгенге көндә дөньяның төрле илләрендә, бигрәк тә Төркия китапханәләрендә татар галимнәренең меңләгән хезмәтләре саклана. Һәм аларның күбесе хәзерге заман теленә күчерелмәгән. Шунысы да билгеле, кайбер китаплар берәр нөсхәдә генә сакланып калган. Үзәк оештыру менә шушы рухи байлыкны халкыбызга кайтару юлында чираттагы бер күркәм адым булыр иде.

Мөфти хәзрәтләре профессор Мехмет Гөрмезне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлеге белән таныштырып, аңар республикадагы дини вәзгыять һәм мөфтият хакында төшерелгән фильмны тәкъдим итте. Әлеге фильм татар, рус, инглиз, төрек телләрендә эшләнде.

Шулай ук мөфти Камил хәзрәт нәзарәтнең алдагы елларга ниятләгән эшләре белән таныштырды. Мехмет Гөрмез мөфтигә һәм республиканың дини делегациясенә мөфтият эшчәнлеге белән таныштырганнары өчен рәхмәтен җиткерде. Ул Төркиянең Дини эшләр идарәсе белән Татарстан мөфтияте арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек алып баруга өметен белдерде.

Мехмет әфәнде үзе дә татар дин галимнәренең хезмәтләрен өйрәнә, хәтта ул татар дин белгече-фәлсәфәче, публицист Муса Бигиевка багышланган докторлык диссертациясе яклаган. Камил хәзрәт белән очрашу барышында да ул XIX гасыр ахыры - XX гасыр башы татар дин белгечләре турында сөйләште.

Мөфтият вәкилләре Коръән өйрәнү буенча уку-укыту программалары белән таныштылар. Төркия Дин эшләре идарәсенең мәгариф департаменты директоры Али Әрбаш мөфтият вәкилләренә уку-укыту программалары турында сөйләде. Аерым алганда, департамент җитәкчесе имамнар өчен Коръән өйрәнү курслары программасы, Изге китапны бала чактан ук яттан белүчеләр – коръәнхафизлар әзерләүгә кагылышлы тәртипләр белән таныштырды.



Моннан тыш Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге ТР МДН делегациясе Төркиягә сәфәре кысаларында Дин эшләре идарәсенең Голәмалар шурасы әгъзалары белән очрашты. Очрашуда Татарстан мөфтие нәзарәтнең Голәмәләр шурасы эшчәнлеге һәм үзара хезмәттәшлек итү мөһимлеге хакында җиткерде. Төркиягә сәфәр кысаларында диния нәзарәте делегациясе шулай ук Әнкара дәүләт университетында булды. Биредә алар теология факультеты белән таныштылар. Университетта мөфтигә Муса Бигиев, Ризаэддин Фәхреддин, Шиһабетдин Мәрҗани турындагы төрекчә китапларны бүләк иттеләр.

Татарстан вәкилләрен уку йортында профессор Исмәгыйль Хаккы Унал каршы алды. Остаз әфәнде университетның уку-укыту программалары хакында сөйләде. Татарстанлылар университет аудиторияләрен, китапханәсен карагач, студентлар белән аралаштылар. Биредә безнекеләр Россия ислам институтының рәсми юлламасы нигезендә магистратурада укыйлар, татар дин әһелләре мирасын өйрәнәләр.

Мөфтият вәкилләре Төркиянең дин эшләре буенча идарәсенең "Вәкыф динәяте"ндә булды. Биредә оешманың попечительләр шурасы рәисе Мәзһәр Билгин белән очрашу үтте. Татарстан кунакларын Төркиянең вәкыф системасын үстерү тәҗрибәсе белән таныштырдылар һәм бу юнәлештә үзара хезмәттәшлек итү юлларын барладылар. Моңардан тыш, Төркиянең дин эшләре буенча идарәсенең мәгариф департаменты директоры Али Әрбаш һәм Халыкара департамент җитәкчесе Хәлиф Кескен белән дә очрашулар булды. Анда үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләре каралды.

ТР МДН делегациясе Истамбул шәһәрендә нәтиҗәле очрашулар үткәрде. Истамбул шәһәренең Аййуп районы мөфтие Мүәммәр Әйән татарстанлылар хөрмәтенә бәйрәм табыны оештырды һәм дини оешма эшчәнлеге белән таныштырды. Шуннан соң ТР МДН делегациясе Хасеки һөнәри белем үзәгендә булды. Камил хәзрәт биредә укыту системасы белән танышты, үзәкнең директоры Әдил Бор белән аралашуда Татарстанда дини уку йортлары өчен эшләнгән бердәм уку-укыту стандартлары турында сөйләде. Камил хәзрәт үзәктә белем алучы Урта Азия республикаларыннан килгән шәкертләр белән дә аралашты. Аларга Татарстанда ислам үсеше турында сөйләде.

Истамбул шәһәренә эшлекле сәфәр ISAM исламны өйрәнү үзәгендә дәвам итте. Үзәкнең директор урынбасары Тунҗай Башоглу мөфтият вәкилләренә биредә алып барылган эшчәнлек турында сөйләде. Китапханә, тикшерү лабораториясе һәм бина үзенчәлекләре белән таныштырды.

ТР МДН делегациясе Истамбул мөфтие Рахми Яран белән очрашты. Яран Камил хәзрәт белән сөйләшү барышында Татарстанга күптән түгел кылган сәфәре турында җылы искә алды. "Китаплар нәшер итү, фән һәм мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлегебезне ныгытырга кирәк, чөнки Төркия һәм Татарстан мөселманнарының дустанә мөнәсәбәте бай тарихка ия. Без бер-беребезне кайгыртып яшәргә тиеш", - диде мөфти Рахми Яран. Очрашу барышында ике мөфтият җитәкчесе бүгенге көндә ирешкән уңышлар турында сөйләде, тәҗрибә уртаклаштылар һәм мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек итү буенча фикер алышты. Камил хәзрәт Татарстан мөфтиятенең проектлары турында сөйләде, ТР МДН эшчәнлеген чагылдырган видеопрезентация күрсәтте. Хөрмәт йөзеннән ике мөфти бер-берсенә истәлекле бүләкләр тапшырды.

# РЕКТОРНЫ ЮБИЛЕЕ БЕЛӘН КОТЛАДЫЛАР



**Татарстан мөфтие урынбасары, Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшинга 60 яшь тулды. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Рәфыйк әфәндене Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исеменнән юбилее белән котлады:**

"Рәфыйк хәзрәт, Сез Россия мөселманнарына дистә еллар дәвамында динебез үсеше өчен зур тырышлыклар куючы галим, остаз, зыялы, мөхтәрәм шәхес буларак билгеле. Дини мәгариф, фән өлкәсендә киң колачлы эшчәнлек алып баруыгыз барча татарларда соклану, ихтирам хисе уята! Бүгенге көндә Сез укыткан, киңәш биргән һәм ярдәм кулы сузган йөзләгән шәкертләр өммәтебезгә тырышып хезмәт итә. Иманлы, динле һәм нык рухлы булырга чакырып кылган күркәм гамәлләрегез безгә дини эшчәнлек алып баруда үрнәк булып тора. Динебез, республикабыз һәм халкыбызның алгарышы өчен куйган хезмәтегез өчен Аллаһы Тәгалә үзегезне, гаиләгезне, туганнарыгызны нигъмәтләре белән куандырып торсын, күңел тынычлыгы бирсен! Эшләрегезне уң кылып, изге гамәлләрегезнең әҗер-савапларын мулдан бирсен! Раббыбызның чиксез рәхмәтенә, дөньяахирәт бәхет-сәгадәтенә ирешергә насыйп итсен.

Аллаһка итәгать итеп, ярдәменә өметләнеп кылган догаларыбыз кабул лардан булып, илкөннәребезгә тынычлык-иминлек, бәрәкәт язсын! Амин".

Рәфыйк Мөхәммәтшин Татарстан Республикасының "Аеруча хезмәт күрсәткән өчен" медале белән бүләкләнде.

Әлеге зур бүләк республиканың дәүләт, икътисад, социаль һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен бирелә.

# НИЯЗ ХӘЗРӘТ САБИРОВ – ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ӘГЪЗАСЫ



**ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан идарәсе каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы булды. Ул Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан идарәсенең киңәйтелгән утырышында да катнашты.**

Хәзрәт үзенең дәгъвәтләү эшчәнлегендә бурычлы кешеләрдән алимент түләтү мәсьәләсенә аеруча зур игътибар бирә. 2014 елда гына да бурычлылар саны 40 970кә җиткән. Мөселман дин әһелләре исә бу күрсәткечләрне кимету максатыннан һәр көн халык арасында аларның хокуклары һәм бурычларын аңлату юнәлешендә зур эш алып бара.

# БЕРЕНЧЕ "КИЗЛӘҮ УКУЛАРЫ" УЗДЫРЫЛДЫ

**Нурлат районының борынгы, тарихи авылы Кизләүдә беренче мәртәбә "Кизләү укулары" оештырылды. "Кизләү укуларын үткәрү безнең бурыч. Чөнки без җирлек халкына, яшьләргә шәригать кушканнарын аңлатырга, татарларның ислам тарихын өйрәтергә тиеш", - дип сөйләде Нурлат районы имам-мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов.**

Кизләү авылы тарихы XVIII йөз башына барып тоташа. Данлыклы Кизләү мәдрәсәсендә үз заманында Утыз Имәни, Нәҗип Думави кебек танылган шәхесләр гыйлем алган.

Бүгенге көндә Кизләүдә ике мәчет бар. Дини, фәнни чара яңа мәчеттә узды һәм анда өлкәннәр дә, яшьләр дә катнашты. Дин әһелләренең тирән эчтәлекле вәгазьләре, җирлек тарихы турындагы чыгышлары берәүне дә битараф калдырмады.

Мәчет имам-хатыйбы Илшат хәзрәт Динмөхәммәтов фикеренчә, яшьләр авылда бер җәмәгать булып оешып киләләр. "Аларга динебезне, тарихыбызны аңлату өчен шушындый мәҗлесләр бик тә кирәк", - диде ул.

"Кизләү укулары"н алга таба республика күләмендә оештырырга ниятлиләр.

# МӨСЕЛМАН ЭШКУАРЫ КОДЕКСЫ БАРЛЫККА КИЛӘЧӘК

**Февраль аенда Казан шәһәренең Әниләр мәчетендә ТР МДНнең Голәмәләр шурасының һәм Россия мөселман эшкуарлары ассоциациясенең уртак утырышы булды. Ул эшкуарлар ассоциациясенең беренче вице-президенты, башкарма директоры Айдар Шаһимәрданов җитәкчелегендә узды.**

Алар бергәләп Россиядә беренче булып мөселман эшкуары кодексын төзү өчен җыелды. Голәмәләр шурасы әгъзалары бу эшкә югары бәя бирде һәм аның әһәмиятен билгеләде. Әлеге документта мөселман эшкуары үзенең эшчәнлегендә сакларга тиешле төп кагыйдәләр урын алачак.

## Рөстәм ХӘЙРУЛЛИН:

# "АРАЛАШЫП ЯШӘРГӘ КИРӘК"



**Мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин Казахстанда беренче мәртәбә үткәрелүче имамнар җыенында катнашты. Чара кысаларында Казахстанда яшәүче мөселманнарның тормышы һәм дини эшчәнлеге белән якыннан танышу, үзара элемтәләр урнаштыру, тәҗрибә уртаклашу ниятләнелгән иде.**

"Ислам - тынычлык һәм татулык дине" дип аталган форумга Казахстан имамнары чакырылган. Форум алдыннан "2020 елга кадәр Казахстан мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлеген үстерү концепциясе" һәм башка документлар әзерләнгән. Әлеге документлар тынычлык, ватанпәрвәрлек, милли гореф-гадәтләргә хөрмәт, Казахстан халкының үзенчәлекләре, гаиләләрне, тирә-як мохитне саклауга кагылышлы мәсьәләләрне колачлый.

***

Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН форумнан алган тәэсирләрен, Казахстандагы дини тормыш турындагы фикерләрен газета укучыларыбызга да җиткерде:

- Төрки кардәшләребез казахлардан чакыру килгәч, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе сәфәрдә булу сәбәпле, анда мине җибәрде. Элек бер дәүләттә яшәгән, төрки тамырлы халык белән, аларның дин әһелләре белән, әлбәттә, безнең элемтәләр моңа кадәр дә бар иде. Берничә ел элек Казахстан мөфтие Ержан кажы Маямеров үзе дә Болгарга килеп китте.

Астанада безне мөфти хәзрәт үзе каршылады, зурлап кунак иттеләр. Без, үз чиратыбызда, аларга мөфти Камил хәзрәтнең сәламнәрен җиткердек. Аралаша торгач, шул да ачыкланды - Казахстан мөфтие Татарстанда, Чаллы шәһәрендә хәрби хезмәттә булган икән, безне якын күрүе шуның белән дә бәйле, ахры.

Казахстанның Диния нәзарәте Алматыдан башкалага - Астанага күчкән. Барлык чаралар да шушы шәһәрдә узды. Беренче көнне мөфтиләр белән аларның Хәләл комитетында очраштык. Татарстан, Кыргызстан һәм Казахстан бергәләшеп зур эшкә тотынырга - хәләл индустрияне үстерүгә керешергә ниятлиләр. Бу өлкәдә мөфтиятләр арасында хезмәттәшлек турында меморандум әзерләнә. Узган ел азагында Казахстан делегациясе Татарстанга да килеп киткән иде. Ул вакытта "Хәләл" стандарт комитеты белән хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнаштыру турында сүз барды.

Хәзерге вакытта хәләл дигән сүз модага кереп китте бит. Кем тели - шул тота да үз товарына хәләл дип язып куя. Безнең арада махсус икътисади зона булгач, хәләл мәсьәләсенә игътибар итү аеруча мөһим, чөнки алар җитештергән продукция - безгә, безнеке аларга керә. Монда хәләл дигән товарны тикшереп үткәрү турында сүз бара. Менә шуны тормышка ашыру ниятеннән Казахстан, Кыргызстан һәм Татарстан зур эшкә тотыналар, Аллаһы боерса.

Астанада мөфти хәзрәтнең урынбасарлары белән танышып, алардагы дини белем бирү системасы эшчәнлеге белән дә кызыксындык. Аларда да бездәге шикелле бер дини университет, 10 мәдрәсә, берничә Коръәнне өйрәнү үзәге эшли икән. Тагын бер әйбергә игътибар иттем, безгә дә Аллаһы тәгалә шуны күрергә насыйп итсә иде - Диния нәзарәтенең хөкүмәт ярдәме белән эшләүче мөселман телеканалы бар. Кайсы өйгә керсәң дә мәш килеп шул каналны карыйлар. "Иман" журналы, газеталары зур-зур тиражлар белән тарала. Барлыгы 2,5 мең ярым мәчет исәпләнә. Без таныштыкан шушы "Ислам - тынычлык һәм татулык дине" дип аталучы Казахстан имамнарының беренче форумына 500 имам (һәр бишенче имам) килгән иде.

Зур иске мәчеткә кереп чыктык, янәшәсендә генә мәдрәсә эшләп тора. Анда бездән - Россиядән килгән берничә казах баласы укый икән. Астанада барлыгы сигез мәчет, төп мәчетләре - "Хәзрәт Солтан"да булдык. Казахлар һәр җомга вәгазен бастырып, яздырып халыкка тараталар. Аллаһы тәгалә бездә дә шуларны эшләргә насыйп итсә иде.

Һәрберебез үз мәчетләребездә, үз мөфтиятендә ябылып кына да ята алабыз, билгеле, әмма аралашу, тәҗрибә уртаклашу кирәк. Шул ук укыту системасында да кулга-кул тотынышып эшләргә була. Исламдагы чит агымнар, дибез икән - аларда да шул ук проблема. Алга таба да мөселманнар, төрки кардәшләребез белән аралашып, тәҗрибә уртаклашып, каршылыкларны гыйлем белән җиңеп яшәргә насыйп итсә иде.

# МӨГАЛЛИМНӘР ГАКЫЙДӘНЕ УКЫТУ ПРОБЛЕМАЛАРЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕ

**ТР МДН һәм Казан (Идел буе) федераль университеты Казан Нуры мәчете каршындагы Шамил мәдрәсәсе белән берлектә "Мәчетләр каршындагы курсларда гакыйдәне (ислам тәгълиматын) укыту проблемалары" темасына түгәрәк өстәл оештырды. Сөйләшүгә Татарстанның төрле районнарыннан мөгаллимнәр җыелган иде.**

Шамил мәдрәсәсе директоры Камил Вәлиуллин үзенең чыгышында мәдрәсәнең эшчәнлеге турында сөйләде. Мәдрәсәгә һәр елны 150гә якын бала кабул ителә һәм алардан 2-4 яшьтәгеләр, 5-6 яшьтәгеләр һәм 6-7 яшьтәгеләр өчен 3 төркем туплана. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар дәресләрдә ата-аналары белән бергә катнаша. Алар кызыклы уен формасында оештырыла. Белгечләр фикеренчә, бу уку-укыту процессына уңай йогынты ясый. Мисал итеп чарага килүчеләргә дә берничә дәрес күрсәттеләр. Мөгаллимнәр балалар белән эшләүдә нинди материаллар һәм методикалар куллану серләре белән бүлеште. Соңыннан мөгаллимнәр үзләре дә, укучы роленә кереп, дәрестә катнаша алды.



Мәчет каршындагы курсларда ислам тәгълиматын укыту проблемалары турында сөйләгәндә катнашучылар дини белем бирүдә комплексы караш кирәклегенә басым ясады. Ирекле фикер алышу барышында гакыйдә фәнен төрле яклап тирәнтен өйрәнү, татар җәмгыятендә аның үсеш юлларын ачыклау, аны укытуда яңа методикалар куллану әһәмияте турында да әйттеләр.

# Тәвәккәл итү (Аллаһы Тәгаләгә тулысынча тапшыру)

**Рәхимле вә шәфкатьле Аллаһ исеме белән... Бар мактауларыбыз да Раббыбызга - дөньялар Хакименә генә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә һәм сахабәләренә Аллаһның рәхмәте вә сәламе ирешсә иде!**

Мөхтәрәм мөселманнар!

Ислам шартларының берсе - Аллаһка таяну һәм Аңа тапшыру. Әгәр нинди дә булса берәр эшкә керешергә уйласак, без: "Аллаһка тапшырдык", - дибез, шулай итеп, үз гамәлләребезнең язмышын Аның ихтыярына тапшырабыз, Аңа өмет баглыйбыз, Аңа таянабыз. Шул рәвешчә гамәл кылып, бик дөрес эшлибез дә. Ул безнең өчен иң хак, иң дөрес, иң яхшы, иң файдалы юлны сайлап алачак, чөнки, безнең бар эшләребез, бар гамәлләребез дә ахыр чиктә Аңа әйләнеп кайта.

Дәлилләр кирәкме? "Җирдәге вә күкләрдәге яшерен бар нәрсәләр Аллаһы тәгаләнеке, вә барча эш Аңарга кайтыр, Аңа - Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз вә Аңа - Аллаһка тәвәккәл кыл! Сезнең кылган гамәлләрегездән Раббың гафил түгел" ("Һуд" сүрәсе, 11:123).

Кызганыч ки, хәзерге көндә кешеләрнең күбесендә Аллаһка өмет баглау дигән әйбер калмады, аларның һәрберсе үзе турында, җәмгыятьтә тоткан урыны, финанс хәле турында уйлый. Берсе дә: "Барысы да - Аллаһ ихтыярында, бар авыр мәсьәләләрнең чишелеше дә Аллаһ кулында", - дими. Безнең күңелләребез зәгыйфьләнде, алар авырый, алар сырхау. Зәгыйфьләнгән күңелләребез Аллаһка булган ышанычны, Аллаһка ышанып тапшыруны, Аллаһка өмет баглауны югалткан. Дөньяви кыйммәтләр өстенлек иткән бу заманда, шулкадәр күп максатларга ирешергә кирәклекне күреп, кешеләр болай дип зарлана: "Ничек итеп мин боларның барысына да ирешә алыйм?", "Ул кадәр балаларны ничек итеп асрамак кирәк?", "Мин аларның киләчәген ничек итеп тәэмин итә алырмын соң?" Ләкин алар бу проблемаларның уңай чишелешен тәкъдим иткән түбәндәге аятьне онытып җибәрә: "Кеше илә җенне мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым. Мин кешеләрдән һич ризык теләмим (ягъни сорамыйм), дәхи Мине ризыкландыруларын да сорамыйм. Шиксез, Ул - Аллаһ барча мәхлукатны бик ризыкландыручы вә бик олуг куәт ияседер" ("Зарият (Таратучы)", 51:56, 57, 58).

"Әгәр шулай булган булса", "их, әгәр дә шулай килеп чыккан булса", "шулай эшләгән булсам" сүзләрен онытыгыз. Йокларга яткан вакытта сезнең башларыгыз артык уйлардан азат булырга тиеш. Чөнки кеше үзе йоклап ятканда Аллаһ аның хәлен үзгәртергә, ә бу кеше бу турыда гомумән берни дә белми калырга мөмкин.

Әйдәгез, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән үрнәк алыйк, аның андый хәлләр вакытында ничек гамәл кылуын искә төшерик. Билгеле булганча, ул Аллаһтан башка беркемнән дә курыкмаган. Теләсә нинди хәлдә дә Аңа таянган, Аңа сыгынган. Аңа гына рөкүгъ иткән, Аңа гына сәҗдә кылган. Аллаһтан башка беркемнән берни дә сорамаган. Намазларны бары тик Аллаһ ризалыгын алыр өчен генә укыган, зәкятләрен дә Аның ризалыгы өчен генә биргән. Уразаны да Аллаһ ризалыгын алу өчен тоткан, Аның өчен генә хаҗ кылган.

Коръәни-Кәримдә болай дип әйтелгән: "Әйт: "Укыган намазларым вә бугазлаган корбаннарым фәкать Аллаһ ризалыгы өчен генә эшләнә вә тере булуым һәм үлмәклегем бөтен галәмнәрне тәрбия кылучы Аллаһы тәгалә эше. Аллаһның һич тиңдәше юк вә мин һичкемне, һичнәрсәне Аңа тиңдәш кылмаска, фәкать Аллаһка гына халис кол булырга Аның тарафыннан боерылдым һәм мин мөселманнарның әүвәлемен". Әйт: "Аллаһтан башка бер мәхлукны үземә Раббым итеп алыйммы? Бөтен вөҗүднең, бөтен мәхлукның Раббысы Аллаһ Үзе генә була торып, һәрбер кеше ни кылса да үзе өчен генә кыла һәм гөнаһ йөгген йөкләүче кеше башка һичбер кешенең гөнаһ йөген йөкләп алмас, соңра кайтачак урыныгыз Аллаһ хозурында, Аллаһ динендә ихтилаф кылышканыгыз белән үзегезгә хәбәр бирер" ("Әнгам (Терлек)" сүрәсе, 6:162, 163, 164).

"Аллаһтан башка бер мәхлукны үземә Раббым итеп алыйммы?" Мондый сорау күңелләрне тетрәтә. Җавап барыбызга да билгеле. Аңа Аллаһ Үзе үк җавап бирә: "Бөтен вөҗүднең, бөтен мәхлукның Раббысы Аллаһ Үзе генә". Их, сез, гамьсезләр, бар булганнарның Раббысы билгеле чакта икенче бер Раббы эзләргә кирәкме соң?

Әйдәгез, Аллаһның соңгысе - Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең иманы ничек булуын искә төшерик әле.

Бервакыт Әбү Җәһил Аллаһ рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килгән дә, аңа яный башлаган: "Мөхәммәд, әгәр дә мин синең тагын бер тапкыр намаз укыганыңны күрсәм, мин сине аягым белән изеп бетерәм".

Бу вакыйга - мөшрикләр көчле булып, алар барысын да үз кулларында тоткан вакытта булган. Аллаһ Рәсүле салаллаһу галәйһи вә сәлләмгә бу вакытта аларның юлбашчысы, Аллаһның һәм исламның дошманы Әбү Җәһил янаган.

Ә ул кемгә янаган булып чыга соң? Аллаһның Пәйгамбәре салләллаһу галәйһи вәсәлләмгә, Аның соекләсенә, дөньяга Раббыбыздан иман нуры, Аллаһ ярдәме турындагы яхшы хәбәрләрне китерүчегә. Аллаһның бар дөньяга рәхмәте булараk җибәрелгән Рәсүленә! Коръәндә Аллаһы тәгалә болай ди: "Ий Мөхәммәд галәйһиссәлам, Без сине җибәрмәдек, мәгәр галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек" ("Пәйгамбәрләр" сүрәсе, 21:107).

Менә шулай, Аллаһның дөньяларга рәхмәте итеп кенә күндерелгән Пәйгамбәре салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Әбү Җәһилнең: "Әгәр дә синең тагын бер тапкыр намаз укыганыңны күрсәм, мин сине аягым белән таптап бетерәм", - дип әйтергә кыюлыгы җиткән. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу мөшрикнең сүзләренә колак салганмы, аның янауларыннан куркып калганмы соң? Юк, аның күңеленә курку да, шик тә кермәгән. Киресенчә, ул бар мөшрикләрнең күз алдында намаз укуын дәвам иткән. Намаз укыганда Аллаһны зикер итүдән дә туктамаган. Ул барысы карап торганда сәҗдәгә киткән, рөкүгъ кылган. Бары лаеклыларның лаеклысы - Аллаһка гына рөкүгъ кылырга ярый, башка беркемгә дә рөкүгъ кылынырга тиеш түгел. Башны бары тик Аллаһ каршында гына җиргә иярgә була, башка беркемгә дә баш иярgә ярамый.

Бу вакытта Әбү Җәһил кояш нурларын үзенең кечкенә канатлары белән каплап торырга тырышкан бер черки кебек кенә булып калган. Моны күзәтеп торган башка мөшрикләр Әбү Җәһилне битәрли башлаган: "Син бит: "Әгәр мин Мөхәммәднең тагын бер тапкыр намаз укыганын күрсәм, аны шушы аякларым белән таптап бетерәм", - дип әйтеп, Лут һәм Гүзза белән ант иткән идең. Ул бернигә дә карамый намаз укуын дәвам итә бит". Әбү Җәһил шунда әйткән: "Лут һәм Гүзза белән ант итәм, мин: "Чынлап та, аның тагын бер тапкыр намаз укыганын күрсәм, зур бер таш белән башын ярырмын", - дип әйткән идем. Тик моны эшлим дигәндә генә аның белән үзем арасында ут бөркеп торган бер чокыр күрдем. Аның ялкыны бик көчле иде. Аннан тыш мин анда ниндидер гәүдәләр вә канатлар да күрдем. Шуның аркасында мин әлеге ниятемне башкара алмадым".

Шуңа күрә, нәрсәгә дә булса ният кылсагыз, фәкать Аллаһка гына мөрәҗәгать итәргә, ярдәм кирәк вакытта бары тик Аннан гына ярдәм сорарга, Аны гына зикер итәргә кирәк.

Аннары, гомернең чикләнгән булуын, һәрберебезне кайчан да булса бер вакыт кабергә төшерәчәкләрен без бервакытта да истән чыгарырга тиеш түгел. Аллаһның ярдәме безгә ахирәттәге тормышыбыз яхшы булсын өчен кирәк.

Кадерле мөэмин-мөселман кардәшләрем!

Кабергә төшергәч, сезне уң ягыгызга салачаклар. Сезнең тәнегезгә, йөзләрегезгә туфрак коячаклар. Фәрештәләр килеп сорау алгач, сез тирән йокыга талачаксыз һәм ул йокыдан Кыямәт көнендә генә уяначаксыз.

Сез кәфен дип аталган кимгә төренгән булачаксыз, ул кием бер ел фасылыннан икенче фасылга алмашынып тормаячак, кирәк вакытта сезгә мөрәҗәгать итәр яисә ярдәм кулын сузар өчен якын дусларыгыз да янңыгызда булмаячак. Сезгә бары тик Аллаһ кына дәшәр: "Ий колым минем, алар синең берүзеңне калдырып китте. Синең яныңда калган булсалар да, алардан берниндй дә файда булмаган булыр иде. Синең янда бары тик Мин генә калдым, чөнки Мин шул ки, кем үлемнән хали (азат)".

Ә синең каберең башкаларга көн саен шуны сөйләп торыр: "Мин - ялгызлык урыны. Мин - караңгылык урыны. Мин - золым урыны. Мин - елан һәм кырыгаяклар яшәгән йорт. Минем бар ягымда да туфрак кына. Тәкәбберләнеп минем өстемдә йөрмә. Алдагы көннәрнең берсендә - бәлки иртәгә үк, бәлки аннан да иртәрәк - мин сине үземә алырмын һәм шулай итеп кысармын ки, синең бар кабыргаларың да сынып бетәр. "Хакыйкать дәрьясында йөзәм..." - дигән кеше миннән күп сабаклар ала алыр... Бар кеше дә миннән үтәр. Бары Аллаһ кына бакый (мәңгелек), бары Аллаһ кына үлемнән хали (азат)".

Хөрмәтле мөселман туганнарым!

Төп темага кире әйләнеп кайтыйк әле. Алда искә алынган мөшрикнең сүзләренә игътибар итик: "Мин үз гамәлемне бернич тапкыр эшләп карадым. Тик һәр очракта да аның белән минем арада ут бөркеп торган чокыр пәйда булды, ә аның өстендә ниндидер коточкыч затлар очып йөри иде. Шуңа күрә дә, мин, куркып, кире чигендем". Әгәр дә без Аллаһның Кәламе шәрифтә искә алынган бар хөкемнәрен дә тулысынча тормышка ашыра алсак, безне беркем дә куркыта, өркетә, бернинди көч тә җиңә алмас иде. Әгәр без ислам тормышы белән чынлап торып яши башласак, Аллаһ рәсүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тапшырган динебез бар җирдә дә калкачак, күтәреләчәк, алга китәчәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне сабырлыкка өндәгән. Ул җиңүгә омтылганда бары Аллаһка гына таянган, Аңа сыгынган; гамәлләрне Аның ярдәменә ышанып тапшырганда гына җиңү мөмкин дип өйрәткән. Бары чын күңелдән шуңа ышанган вакытта гына мөмкин. Чын тәвәккәл итү - Аллаһка тулысынча тапшыру, әгәр Аллаһтан ихлас сорасаң, Ул аны башкарырга һичшиксез ярдәм итәчәгенә ышану ул.

Хәзер исә, Әбү Җәһил Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне аягы белән сытам дигәч, аңа индерелгән аятьләрне карап китик: "Әйә күрдеңме, берәүнең намаз уку-



чыны намаздан тыюы тиешме, яхшы эшме? Ул Аллаһ колы - Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең иң зур бурычын үтәү өчен намаз укыганда? Әйә, ул намаз укучы Аллаһ колын намаз укудан тыю дөресме, ул һәркемгә яхшылыкны гына теләүче һәм хак туры юлда булса да. Әйә, ул Аллаһ колын намаз укудан тыю дөрес булырмы, ул кешеләрне Аллаһтан куркырга һәм гөнаһлардан сакланып, изге гамәлләр кылырга өндәсә дә? (Әбү Җәһил бервакыт, әгәр Мөхәммәднең сәҗдә кылганын күрсәм, әлбәттә, аның башын кисәчәкмен дип вәгъдә кылды һәм, Мөхәммәднең сәҗдә кылганын күргәч, теләгән үтәргә ашыгып килде, ләкин барып җитмичә, барча әгъзалары калтыраган хәлдә кире китте. Иптәшләре: сиңа ни булды дип сорады, ул: "Минем белән Мөхәммәд арасында уттан дивар килеп чыкты, аз гына янмыйча калдым", - диде). Әйә, ул намаздан тыючы кяфер, үзе Аллаһ Китабы Коръәнне ялган дисә дә, һәм Раббысына итагать итүдән вә Аңа гыйбадәт кылудан баш тартса да, намаздан тыямы, намаздан тыярга үзен хаклы саныймы? Әйә, намаздан тыючы ул кяфер белмиме Аллаһның һәркемне күргәнен? Юк, алай кирәкмәс, намаздан тыю - ни кабахәт эштер, әгәр ул бу эшеннән туктамаса, әлбәттә, маңгай чәченнән тотып җәһәннәмгә өстерәрбез. Һәр эштә хата, ялган һәм зур гөнаһ кылучының маңгай чәченнән өстерәрбез. (Ул кяфер: "Минем дусларым күп", - дип мактанды.) Намаздан тыючы ул кяфер, чакырсын хәзер үзенең ярдәмчеләрен! Без тиздән газап фәрештәләрен чакырырбыз, кяферләрне җәһәннәмгә өстерәрбез. Юк, кирәкмәс, намаздан тыю - бик яман, кабахәт эштер, аңа итагать итмә, сүзенә колак салма, сәҗдә кыл, намаз укы һәм Аллаһка якын булуны кәсеп ит! (Беренчеләрдән иңгән бу сүрәдә үк Аллаһы тәгалә намаз укырга әмер бирде. Чөнки намаздан башка иман да, дин дә юк. Намаз - диннең йөрәге вә башы) ("Галәк" сүрәсе, 96:9-19).

Ә сөекле Пәйгамбәре салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Ул менә ниләр әйтә: "...Аңа итагать итмә, сүзенә колак салма, сәҗдә кыл, намаз укы һәм Аллаһка якын булуны кәсеп ит!"

Мөхтәрәм мөселманнар!

Аллаһ беркайчан да Аңа өмет баглаган кешегә җиңелү ачысы татырга юл куймаячак. Аллаһ беркайчан да Аннан ярдәм сораган кешеләрне бәладән коркармый калмаячак.

Аллаһның Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм бервакыт Мәккә мөшрикләре янына - Кәгъбәгә якын утырган. Шулчак алар янына Араш кабиләсеннән бер кеше килеп чыккан. Ул андагыларга болай дигән: "Җәмәгать, Әбү Җәһил бурычын кайтармый, кем миңа бурычымны алып бирергә ярдәм итә ала?" Андагы мөшрикләрнең көлеп әйткән җаваплары түбәндәгечә булган: "Безнең арада бурычка биргән акчаңны алып бирергә сәләтле бер кеше бар. Әнә, ул кеше - кызыл киемле, ак йөзле бәндә, ул сиңа ярдәм итәр", - дип, алар Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә төртеп күрсәткән. Араш кабиләсеннән булган әлеге кеше аның Аллаһның Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм икәнлеген белмәгән һәм аңа: "Ий Аллаһның Рәсүле", - диясе урынга, түбәндәгечә мөрәҗәгать иткән: "Ий гарәп туганым! Гамр ибне Һишам миңа акча бурычлы. Син миңа шул бурычны алып бирергә ярдәм итә алмассыңмы?"

Аллаһның бар дөньяга рәхмәте буларак күндерелгән Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм ярдәм итү дигәндә беркемнең дә гозерен кире какмаган, бу юлы да ул әлеге кешегә ярдәм итәргә риза булган һәм бурычын ала алмыйча йөргән шул кеше белән Әбү Җәһилнең өенә киткән. Билгеле булганча, Әбү Җәһил каты бәгырьле кеше булган, ул беркемгә дә ярдәм итәргә яратмаган. Ләкин Раббыбызның сөеклесе - Аллаһның Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркемнән дә курыкмаган. Алар теге кеше белән Әбү Җәһилнең капкасын какканнар. Эчтән: "Кем анда?" - дигән тавыш ишетелгән. Аллаһның Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм) аңа: "Бу мин, Мөхәммәд", - дип җавап биргән. Әбү Җәһил капканы ачып сораган: "Сиңа ни кирәк, Мөхәммәд?" Аллаһның Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа болай дигән: "Синең бу кешегә күпме бурычың булса, шуны кире кайтарып бир!"

Моны ишеткәч, Әбү Җәһил өенә кереп киткән һәм тиешле акчаны алып чыгып биргән. Бурычын ала алмыйча йөргән кеше моңа бик тә куанып, Әбү Җәһил кире уйлаганчы дип, тизрәк китеп барган. Бу кешене күргән мөшрикләр аннан: "Әбү Җәһил бурычын сиңа кире кайтардымы?" - дип сораган. Ул кеше: "Әйе, ул барысын да кире кайтарып бирде, Аллаһ Мөхәммәдтән разый булсын", - дип җавап биргән.

Моны ишеткән мөшрикләр, Әбү Җәһилнең өенә барып, аны чакырып чыгарганнар да: "Ий Әбү Хәкам. Син нәрсә, әллә Мөхәммәдтән курыктыңмы? Әгәр дә бу чынлап та шулай икән, нишләп йөрибез без монда?" - дип сораганнар. Әбү Җәһил аларга гаҗәеп рәвештә җавап биргән: "Лут һәм Гүзза белән ант итәм, капканы ачкач, мин Мөхәммәдне күрмәдем, аның урынына анда бер арыслан тора иде. Әгәр мин бер генә сантиметрга алга чыксам да, ул мине тотып алып, өзгәләп ташлар иде".

Хөрмәтле мөселманнар!

Аллаһка таянуның нинди нәтиҗәләргә китергәнен күрдегезме? Димәк, Аллаһның Үзеннән генә курыккан кешедән - калган бар кеше дә куркачак. Ә Аллаһтан курыкмаган кеше - калган бар кешеләрдән дә куркачак, хәтта кеп-кечкенә мәче балаларыннан да.

Әгәр без Аллаһка өмет багламыйча яшәсәк, безгә түбәндәге аятьтә күрсәтелгән нәрсәләр белән очрашырга туры киләчәк: "Яки ул имансыз рәвештә дин тотучыларның гамәлләре (тирән диңгездә дулкынланудан барлыкка килгән караңгылык кеби). Ул диңгезне дулкын каплый, ул дулкын өстеннән янә дулкын каплана, вә ул дулкын өстен кара болыт каплыйдыр, ошбу караңгылыклар - берсе икенчесенең өстенә караңгылыктыр. Ошбу катлы-катлы караңгылык астында калган кеше - әгәр кулын чыгарса - ифрат караңгылыктан кулын күрергә дә якын булмас. Аллаһ кемгә иман нуры бирмәсә, әлбәттә, аның иман нуры булмас!" ("Нур" сүрәсе, 24:40).

Мин сезгә Аллаһка дөрес итеп таяна һәм сыгына белүнең ни икәнен яхшы аңлаган бер кешене мисал итеп китерәсем килә. Ул - Әбү Хәсән Әхмәд ибне Бенан атлы галим (Аллаһ аңардан разый булса иде). Бану Тулун династиясе хакимлеге вакытында Әхмәд Тулун атлы бер хаким үз халкын зур золымлыкта тоткан. Халык вәкилләре галимнән ярдәм итүен үтенгәннәр: "Барып сөйләшеп кил әле, безне җәберләүдән туктасын, гаделлек белән хакимлек кыла башласын".

Ә хакимне аннан нык курыккан кешеләр уратып алган. Алар аны, үзләренә файда алу өчен, бер сәбәпсезгә мактый торган булган. Галим, хакимгә барып, болай дигән: "Җитәр сиңа, үз халкыңны бик күп рәнҗеттең. Син алар өчен шактый яманлыклар кылдың инде".

Мондый мөгамәләгә күнекмәгән хаким, галимне бәйләп куярга һәм аны өч көн буена ач торган арыслан белән бер бүлмәгә бикләргә кушкан. Аның хезмәтчеләре барысын да хаким кушканча эшләгән; галимне өч көн буе ач торган арыслан янында калдырганнар. Бераз вакыттан соң Әхмәд Тулун һәм аның яраннары галим белән ни булуын карарга дип килгәннәр, бүлмәнең ишеген ачкач, алар менә ни күргәннәр: олуг галим сәҗдәгә киткән, ә арыслан, бер почмакка посып, аны күзәтеп тора икән. Әгәр бу вакытта Аллаһның саклавы һәм шәфкате булмаса, бу галим сәҗдә кыла алган булыр идеме? Ә бу ач арыслан аны тыныч кына күзәтеп торыр идеме?

Тәкъдирләр Хакиме рәхсәтеннән тыш, беркем беркемнең дә җанын ала алмый, барысы да Аның хөкемендә - җан иясенә бүлеп куелган ризык та, Ул яраткан бар мәхлукларның җаннары да. Беркем дә Ул билгеләгән тәкъдиргә каршы бара алмый.

Әхмәд ибне Бенан белән алга таба ни булганын язып китәсебез килә. Шул рәвешчә, өч көн буе ашамый торган арысланга ашарга дип бирелгән бу галим исән-имин кала. Аны яңадан хаким каршына алып киләләр. Ибне Тулун аннан сорый: "Ул арыслан ничек сине ашамады?" Галим аңа түбәндәгечә җавап бирә: "Мин ач арыслан янына ябылгач, Коръәни-Кәримнең шушы аятен укыдым: "Дөньяда Раббыңның хөкеменә чыда! Бит син Безнең күз алдыбыздасың, аларның сиңа кылган явыз эшләрен (һәм Раббыңны мактап тәсбихләр әйтә торган вакытыңны да) күрәбез" ("Тур (Тур тавы)" сүрәсе, 52:48)".

Кадерле мөселман кардәшләребез!

Аллаһ яклавы булганда берниднән дә курыкмагыз. Бар куркулар да Аллаһка тапшыру каршында юкка чыксын. Үз проблемаларыгызга артык тирән кереп китмәгез. Аллаһка тапшыру күп проблемаларны чишәргә ярдәм итә. Адәм балалары төрле бәхетсезлекләр белән еш очраша. Ләкин көннәрдән бер көнне сезнең бар проблемаларыгыз да чишелер, кайгы-хәсрәтләрегез шатлыкка әйләнер. Сагышлы мизгелләрегезне онытып, аларны тәкъдиргә калдырыгыз. Бар борчуларыгызны куеп, бар проблемаларыгызны да Аллаһка тапшырыгыз.

Кадерле мөселманнар, минем сездән шуны сорыйсым килә: "Аллаһның күзәтүендә булган кешегә борчылырга кирәкме?" Юк, беркайчан да борчылырга кирәкми.

Әйдәгез, күңелләребезне шатлык хисе белән тутыра торган бу аятьне тагын бер тапкыр укыйк әле: "Дөньяда Раббыңның хөкеменә чыда! Бит син Безнең күз алдыбыздасың, аларның сиңа кылган явыз эшләрен (һәм Раббыңны мактап тәсбихләр әйтә торган вакытыңны да) күрәбез" ("Тур (Тур тавы)" сүрәсе, 52:48)".

Ә Әбү Хәсән Әхмәд ибне Бенан Аллаһ Китабыннан нәкъ менә шуны аңлап алган да. Ибне Тулун аннан болай дип сораган: "Ач арыслан белән йөзгә-йөз очрашкач, син нәрсәдән курыктың?" Галим аңа: "Мин бары тик аның төкереге миңа тиюдән генә курыктым, чөнки аның төкереге - нәҗес, ә ул миңа эләккән булса - намаз укый алмаган булыр идем".

Менә шул була да инде гамәлләреңне Аллаһка тулысынча ышанып тапшыру!

Бар мактауларыбыз да Аллаһка - дөньялар Хакименә!

Раббыбызның Рәсүленә Аның сәламе вә рәхмәте ирешсә иде!

***Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***

# МӨСЕЛМАН БУЛМАГАННАР ҖӘННӘТКӘ КЕРӘЧӘКМЕ?

**Бүгенге көндә "Аллаһы тәгалә - бер, ә Аңа илтүче юллар төрле" дигән фикер киң таралган. Күпчелек дөреслекнең чагыштырмача булуын, һәр халыкка үз диннәре әлегә һәм бу диннәрнең, бер-берсеннән аерылуларына карамастан, барысының да дөрес һәм Аллаһыга шулай кирәк булуын раслый. Мондый фикерләр ялган һәм бик хәтәр адашу. Ислам - бердәнбер дөрес дин, аның туры юлыннан бару безне Тәмуг утыннан саклаячак. Коръәни-Кәримдә болай диелгән: "Шиксез, Аллаһы хозурында ислам дине генә хак дин" ("Гыймран" сүрәсе, 19 нчы аять).**

Иманлы кеше булу өчен: "Аллаһы тәгалә бар" яки "Мин Аллаһыга ышанам" дип әйтү генә аз. Аллаһы тәгалә турында дөрес күзаллау булганда, Аллаһыны Аңа тиеш булган, лаеклы рәвештә сурәтләгәндә, Раббыбызның кимчелекләре булмауны таныганда гына чын иманлы кеше булырга мөмкин. Боларның барысын да исламда гына табарга була.

Ислам - барлык пәйгамбәрләрнең (галәйһиссәлам) дине. Мөселманнар пәйгамбәрләргә һәм аларның төрле вакытларда бер аллалыкка һәм мөселман булырга өндәгәннәренә инаналар. Бу ислам динендә иман китерүнең мөһим бер өлеше. Чыннан да, пәйгамбәрләрнең барысы да Аллаһы тәгаләгә табынырга өндәгән. Ләкин алар алып килгән кануннар һәм дин кагыйдәләре тора-бара кешеләр тарафыннан үзгәртелгән. Мәсәлән, үзләрен Муса яки Гайсә галәйһиссәламнәрнең дәвамчылары дип санаучылар әлеге пәйгамбәрләр җиткергәннәргә түгел, ә бик нык үзгәрешләр кичергән өйрәтмәләргә ияргәләр. Аллаһы тәгалә өйрәткәннәрне кабул итүдән һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлегенә ышанырга теләүдән баш тарткан кешеләрне берничек тә бер Аллаһыга табынучылар дип санап булмый.

Исламның бер баганасыннан гына да тайпылган кеше имансызга әйләнә һәм, вакытында тәүбәгә килеп, яңадан исламны кабул итмәсә, мәңгелектә гафу кылынмаячак. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сүзләренең дөреслеген кире каккан һәм дингә килергә теләмәгән кешеләр хакында ни әйтә алабыз соң?

**Коръәни-Кәримдә исламның бердәнбер тугры юл булуын раслаучы бик күп аятьләр бар. Мәсәлән: "Берәү ислам диненнән башка дингә иярсә, аның дине вә гамәле һич кабул булмый, ул ахирәттә хәсрәтләнүче вә һәлак булучыдыр" *("Гыймран" сүрәсе, 85 нчы аять).***

Гамәлдән чыгарылган диннәр Аллаһы тәгалә каршында бернинди кыйммәткә ия түгел. Ләкин мөселманнарга җәннәттән урын әзерләп куелган, алар моның белән бик горурланалар, ә башкаларның тәмугта яначакларына бик сөенәләр, дип уйлау ялгыш. Һәр иманлы кеше мөселман булмыйча үлүдән курка. Чөнки дин кешенең шәхси казанышы, аның хезмәтенең нәтиҗәсе түгел, Үзе теләгәннәрне генә тугры юлга өндәүче Аллаһы тәгаләнең бүләге ул. Мөселман һәр кешенең исламны кабул итеп, Раббыбызның рәхмәтенә ирешүен тели. Моның өчен Аллаһы тәгалә җибәргән тугры дингә күнәргә кирәк. Башка юллар ялгыш.

*"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән*



# Мөфтигә соравым бар

***- Минем апам фатирын арендага бирә һәм аренда акчасына яши. Ул зәкятне аренда китергән керемнән түләргә тиешме, әллә фатир бәясеннәнме?***




- "Фәтава әл-Хания" китабының беренче томының 250 битендә болай диелә: "Әгәр дә 10000 дирһәмгә капчык (безнең заманда 1 миллионга машина яки йорт) сатып алынып, кешегә арендага бирелгәннән соң бер ел узса, зәкят бу капчыклардан (йорттан, машинадан) түләнми. Чөнки бу капчыклар аларны сату максаты белән түгел, ә керем алу максаты белән сатып алынган".

Шулай ук "Әд-Дүррүл-Мохтар" китабында болай диелә: "Кулланыла торган киемнән, йорт җиһазларыннан, кеше тора торган фатирлардан һәм йортлардан һ.б. зәкят түләнми".

Тахтавиның бу китапка шәрехләрендә (1т., 392 бит): ""һәм башкалар" дигәндә түбәндәгеләрне күз алдында тоталар: керем китерүче кунакханәләр һәм кибетләр", - диелгән.

Шулай итеп, апагыз фатир бәясеннән зәкят түләргә тиеш түгел, ләкин аренда китергән керем белән аның карамагында булган акча суммасы нисаб бәясенә җитсә (120000 сум), шул суммадан зәкят түләргә тиеш.

Аллаһы Тәгаләгә яхшырак мәгълүм.

***

***- Узган елның 6 маенда ислам динен кабул иттем, күп нәрсәне белмим, зәкят турында сорыйсым килә. Мин пенсиядә, пенсиям - 7250 сум, эшләмим. Мин зәкят түләргә тиешме? Аны ничек исәпләргә?***

- Ислам динен кабул итүегезгә без бик шат, Аллаһы тәгалә сезне ике дөнья



бәрәкәте белән бүләкләсен!

Әт-Тахтави" китабының 4-нче томының 160-нчы битендә болай диелә: "Фәтава әл-һиндия"дә китерелә: Бай (зәкят түләргә тиеш) кешенең 200 дирһәм яки 20 динар акчасы (85г. алтыны, безнең көндә 120 000 сум) яки, торак, машина, көн дә кирәк булган әйберләр (кием-салым, телефон һ.б.), йорт җиһазларыннан тыш, бу суммага тиң товары булырга тиеш.

Әгәр дә сезнең бер елдан артык сакланган 120 000 сум акчагыз юк икән, сез зәкят түләргә тиеш түгел.

Аллаһы Тәгаләгә яхшырак мәгълүм.

# ҖОМГА НАМАЗЫ

**ВӘГАЗЬНЕҢ СТРУКТУРАСЫ**

Җомга намазы ике өлештән - хөтбә һәм вәгазьдән тора.

Вәгазь шулай ук ике өлешкә - нәсыйхәт һәм рәсми өлешкә бүленә.

**Хөтбә**

Аллаһыга мактаулар (зикерләр) булган хөтбә тирән эчтәлекле җомга намазының шарты булып тора. Хөтбә шулай ук ике өлештән тора. Беренче өлештә Аллаһы тәгаләгә зикер әйтелә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаилә әһелләренә, гадел хәлифләргә һәм көрәштәшләренә изге теләкләр, тәшәһһөд, диндәшләргә үгет-нәсыйхәт әйтелә, Коръәни-Кәримнән өзекләр китерелә. Икенче өлештә тәкъвалыкның башка рәвешләреннән тыш имам дингә ышанучылар өчен дога кыла. Хөтбәнең ике өлеше бер-берсеннән имамның бераз утырып торуы белән бүленә.

Хөтбә җомга намазы кергән вакыттан намаз башланганчыга кадәр укыла.

Хөтбә гарәп телендә укыла.

**ВӘГАЗЬ**

Вәгазь җомга намазы кергәнче укыла.

Вәгазь хөтбәгә өстәмә булырга, ягъни җомга намазы җиткәч тә укылырга мөмкин.

**Җомга намазын үткәрү тәртибе**

***1 НЧЕ ВАРИАНТ***

Җомга намазы җиткәнче имам дин тотучыларга вәгазь белән мөрәҗәгать итә.

Мәзин җомга намазына чакыра торган беренче азанны әйтә.

Имам һәм мәхәллә халкы дүрт рәкәгать сөннәтне укый.

Мәзин җомга намазына чакыра торган икенче азанны әйтә.

Имам мөнбәргә күтәрелә.

Имам хөтбәнең беренче өлешен сөйли.

Имам мөнбәр баскычына утыра (ике вәгазь арасында утырып тору).

Имам хөтбәнең икенче өлешен укый.

Имам җомга намазының фарыз өлешен башкару өчен мөнбәрдән төшә.

Мәзин җомга намазының фарыз өлешен башкаруга чакыручы камәт әйтә.

Имам җитәкчелегендә мәхәллә мөселманнары җомга намазының фарыз өлешен укый.

***2 НЧЕ ВАРИАНТ***

Мәзин җомга намазына чакыра торган беренче азанны әйтә.

Имам һәм мәхәллә халкы дүрт рәкәгать сөннәтне укый.

Имам дин әһелләрен сәламли һәм мөнбәргә менә.

Мәзин җомга намазына чакыра торган икенче азанны әйтә.

Имам хөтбәнең беренче өлешен укый һәм дин тотучыларга вәгазь сөйли.

Имам мөнбәр баскычына утыра (ике вәгазь арасында утырып тору).

Имам хөтбәнең икенче өлешен укый.

Имам җомга намазының фарыз өлешен башкару өчен мөнбәрдән төшә.

Мәзин җомга намазының фарыз өлешен башкаруга чакыручы камәт әйтә.

Имам җитәкчелегендә мәхәллә мөселманнары җомга намазының фарыз өлешен укый.

Җомга намазын кайсы вариант буенча үтәү имам-хатыйб һәм мәхәллә халкы белән килештерелә.

*"Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында НИГЕЗЛӘМӘ"дән*

# БЕЗНЕҢ ЯУЛЫККА НИ БУЛГАН?

**Бисмилләһир-рахмәнир рахиим! Гасырлар буена татарның матур киенергә яратканын беләбез. Ул һәрвакыт өс-башын чиста-пөхтә йөрткән. Яктырак төсне сайлаган, ак, яшел төсләрдәге киемгә өстенлек биргән. Ашамаса ашамаган, хәтта авыр сугыштан соңгы чорда да өй тирәсен карап, рәшәткәләрен яшел, зәңгәр буяу белән буярга тырышкан.**

Дин сабагы укытылмаган заманнарда гына кайбер милли гореф-гадәтләребез зәгыйфьләнде. Бу бигрәк тә киемнәребезгә кагыла. Үз телебездә сөйләшми башлау белән гореф-гадәтләрдән ераклаштык шул. Рус телендә сөйләшә башладык, аның киеме, гореф-гадәте килеп керде. Бала итәкле күлмәкләребезне салып, "юбка" кидек. Мода, имеш. Еллар үткән саен модалар да алышына барды. Дини мәгълүматны өйрәнүгә игътибар итү белән янә башка яулык бәйләнә башлады. Дингә рөхсәт бирелгән чорда татар халкына төрекләр киемнәр белән күп ярдәм итте. Аллаһның рәхмәте булсын! Әлбәттә, алар безгә үз киемнәрен, яулыкларын җибәрделәр. Яңа гына дингә килгән, үзенең тарихын, гореф-гадәтләрен белмәгәне, без шушы киемне кияргә тиешбез, дип шатлана-шатлана бушлай килгән киемнәрне кия башлады. Шулай итеп, яулыкларны өчпочмаклап бөркәнеп, муен өлешендә булавка белән беркетеп кую модага керде. Күбрәк яшь кызлар, яшь ханымнар арасында таралган бу мода олы яшьтәгеләргә дә күчте. Татар халкының бик исе китмәсә дә, башка милләт кешеләренә бу охшап бетмәгән, күрәсең...

Менә беркөнне өемә өч рус хатыны килеп керде. Исәнләштек, күрештек. Гадәттәгечә, миңа кем килсә дә үз туганым кебек каршы алам. Нигә килгәннәрен дә сорамадым, алар да әйтмәде. Чәй янында сөйләшә торгач, сер ачылды. Боларга татарларның яулык бәйләү рәвеше ошамый икән. "Элек татар хатыннары сезнең кебек дүртпочмаклап ак яулык бәйлиләр иде, без дә соклана идек. Әйтегез әле, ни булды аларга? Нигә татарлар яулыкларын элеккечә бөркәнми башлады?"

- Әйе, шулай. Сез дөрес сөйлисез, - дим. - Борынгылар күбрәк ак яулыкны дүртпочмаклап бәйләгәннәр. Йон, кәшемир, ефәк яулыклары төрле төстә - яшел, зәңгәр, кызыл, чәчәкле-чуклы да булган. Әмин үзем ак төсне күбрәк яратам, калган төсләр миңа килешми сыман... Бездә беренче чиратта киемнең төсе түгел, аның чиста, пөхтә, ару булуы мөһим (өч мәртәбә чайкалган булырга тиеш). Боларны безгә бала вакыттан ук өйрәтә башлыйлар, чөнки ислам дине шуны таләп итә. Ислам дине - пакьлек, тынычлык дине, миллätебез - тынычлык сөюче, чисталык яратучы милләт. Хәтта синең кигән киемең дә кешеләрдә матур, җылы тәэсир калдырырга тиеш.

- Без дә шулай дибез, татарларның гореф-гадәтләре, дүртпочмаклы ап-ак яулыклары үзенә күрә бер ямь, җылылык, матурлык бирә иде ич, - диләр.

- Рәхмәт килүегезгә! - дим нәрсә әйтергә дә белмичә.

Урамда, юлда, тукталышларда, күршеләр тарафыннан үзем гел рәхмәт ишетәм, әмма мин моңа ул кадәр игътибар да итми идем. Яшь кызлар, киленнәр хәзердән үк минем кебек яулыкларын дүртпочмаклап ябып йөрмәсләр бит инде, дип фикер йөртә идем. Чакырылмаган кунакларым мине уйларымда гына булса да балачагыма кайтарды. Әти-әниләрне, туганнарны, борынгы имамабыстайларны искә төшерәм, берәм-берәм күз алдымнан үткәрәм. Барлык очракта да дүртпочмаклап яулык бәйләү! Бу күренеш безгә бик борынгы әби-бабайларыбыздан мирас булып килеп ирешкән, күрәсең.

Ә киемнәре, сөйләшүләре, үзүзләрен тотышлары, аяк атлаулары? Барысы да безгә үрнәк булган бит. Кунаклар киткәч, әниебез безгә дәрес бирер иде. Алар кебек салмак кына, аякны җиргә тидерер-тидермәс итеп, уртача адымнар белән, гәүдәне төз тотып, ашыкмыйча гына йөрергә өйрәтер иде. Капка астыннан - казлар йөри торган урыннан бу абыстайларны



Акъәбиләр

күздән югалганчы карап калуларым исемдә. Алар су өстендәге ак пароходлар кебек әкрен генә ашыкмыйча гына атлап барырлар иде...

- Сез дөрес сөйлисез, ханымнар. Без татарлар элеккеге гореф-гадәтләребезне куллanмый, милли киемнәребезне кими башладык шул. Моның төп сәбәбе - үз телебездән баш тартуыбыздадыр. Гаиләдә туган телебездә сөйләшмибез, мәктәп, институтлар да сезнең телдә укыта. Тел белән сезнең гореф-гадәтләрегез, киемнәрегез килеп керде. Үзебезнең бала итәкле күлмәкләребезне, дүртпочмаклап бәйләнгән ак яулыкларыбызны хәзер сәхнәләрдә һәм Коръән ашларында гына күрә башладык.

Соңгы елларда мөслимә туташлар, ханымнар арасында озын, җирдән сөйрәлеп йөри торган күлмәкләр, итәкләр модага керде. Менә бусы инде күңелне иң борчый торган күренеш, чөнки намаз укыганда һәрнәрсә дә - тәнең, күлмәгең, башкасы да ару, чиста булырга тиеш! Ә бүгенге яшьләребезнең күлмәк итәкләре урам пычрагын җыеп йөри. Алар шул көенчә намазга да басалар. Мине күбрәк пычрак кием борчый, дим боларга.

Яулыкка килгәндә, яшьләребезгә, минем кебек борынгыча дүртпочмаклап бәйләгез, ул ак төстә генә булсын, дия алмыйм. Кемнең әле карчык буласы килсен! Шуңа күрә мин аларга, шарфларыгызны баш артында бәйләп, бер очы белән муенны каплап, колак янына китереп беркетеп куегыз, икенчесен күкрәккә төшерегез, бик матур күренә ул, дим.

Мин үзем пенсиягә чыгу белән ак яулыгымны таратып, дүртпочмаклы итеп бәйләп йөри башладым. Карчыкларыбызның кап-кара яулыкка төренеп, яулыкны өчпочмаклап бөркәнеп, булавка белән эләктереп йөргән үзем дә ошатып бетермим. Шулай да гимназиядә "Диннәр тарихы һәм гарәп теле фәннәрен" укытканда бер мәртәбә яулыгымны аларча бәйләп барган идем.

Әмма укучылар кабул итмәде. Сезгә татарча ак яулык килешә, башка бәйләмәгез, диделәр. Шуннан соң мин үзебезчә генә бәйли башладым. Әниебезнең барлык як яулыкларын тузганчыга кадәр бәйләп бетердем. Элек алырга киеме дә юк иде бит. Хәзер генә ул ни теләсәң шул бар, акчаң гына булсын!

Кунакларны озаткач, шактый гына уйланып утырдым. Нигә бу турыда бер дә фикер йөртмәдем икән мин? Дөресен әйткәндә, Коръән ашларында яулыкларын өчпочмаклап бөркәнеп, муен тирәсендә булавка белән эләктергән карчыкларны күреп, күңел кимсенеп куя. Кайберсе белән сөйләшеп тә алам. Алар: "Мөселман хатын-кызларының бөтен җире томаланган булырга тиеш, без дөрес киенәбез", - диләр. Мин әтиебез белән аралашкан-йөрешкән 17 имамның абыстайларын күреп үстем. Барысы да таратып бөркәнгән ак яулыктан, кәшемир, йон яулыктан, иңнәрендә ефәк шәл яки ак оренбур шәле булыр иде. Барысында да ирләре яраганны-ярамаганны белүче коръәнхафизлар иде. Уйлана-эзләнә торгач, иске журналлардан күп кенә фоторәсемнәр табып алдым. Барысында да дүртпочмаклы яулык!

Безнең җирлектә дә мөселман хатын-кызлары күлмәгенең изүе томаланган булырга тиеш. Моны искә алып, бик борынгы заманнарда хатын-кызлар күлмәкнең әченнән яисә тышыннан күкрәкчә кигәннәр. Яулыкны дүртпочмаклап бәйләсә, бугаз өлеше (муены) күренми торган булган. Хәзер дә яулыкны дүртпочмаклап япканда күлмәкнең изүенә игътибар итеlә, күлмәк изүе тән күренмәслек итеп тегелә. Борынгыдан килгән, вакыт сынавын үткән киемнәребез, үзебезгә генә хас яулык бәйләү рәвеше - болар бит безнең милли байлыгыбыз.

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ!

**Сәйдә абыстай АППАКОВА**



Элек кыз балалар яулыкны менә шулай бөркәнгән

**РЕДАКЦИЯДӘН.** *Сәйдә абыстай гап-гади дә,бик четерекле дә мәсьәлә күтәргән. Дөресен генә әйткәндә, бу хактагы бәхәсләр инде утыз ел дәвам итә.*

*Чынлап та, нигә әле без үзебезнең милли киемнәребездән, үзебезгә генә хас булган яулык бөркәнү рәвешеннән баш тартабыз? Ул бит барыбызга да бик ошый, ак яулыклы акъәбиләрне күреп кем генә сокланмый икән! Көннәрдән беркөнне барлык татар мөслимәләре - хәтта япь-яшь кызларыбыз да ап-ак яулыкларын дүртпочмаклап бөркәнеп урамга чыкса, башка килгән беренче уй ни булыр иде икән? Болар кайсы театр сәхнәсеннән? Флешмобмы? Шул шул, яшьләр чын тормышта яулыкны болай бөркәнеп йөрми. Ну, яшьләрчә түгел! Ә менә башларына түрбан киеп, шарфны әллә ниләр кыландырып урап йөргән хәзерге модница-мөслимәләребез картайгач, сандык төбеннән ак яулыкларын сөйрәп чыгарып, аны дүртпочмаклап бәйләрләр дисезме? Гомумән, милли киемнәребез, ак яулыгыбыз, дип тартышып яту кирәк микән бүгенге заманда? Шәригатькә туры китереп башыбыз капланган, диярә дә мәсьәләне куертып тормаска кирәктер, бәлки?*

*Кыскасы, хөрмәтле укучыларыбыз, бу бәхәсле темага сезнең дә фикерләрегезне беләсебез килә. Бәхәсләшик, фикерләшик, киңәшләшик әле. Адресыбыз шул ук: Казан, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт; naubahar67@list.ru.*

# МӘХӘББӘТ АША МӘРХӘМӘТЛЕЛЕККӘ ЧАКЫРУ

**Татарстанда Мәүлид ае "Мин Пәйгамбәребезне яратам" акциясе белән тәмамланды. Төп чара башкаланың Кол Шәриф мәчетендә җомга намазыннан соң булды. Җомга намазы вәгазе Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланды. Аннары Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә эшләүче яшьләр волонтерлар белән бергәләшеп намазга килгән барча халыкка "Мин Пәйгамбәребезне яратам" дигән сүзләр язылган түштамгалар һәм кечкенә әләмнәр өләштеләр. Шулай ук хәзрәтләребез - Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров һәм Кол Шәриф мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов матбугат вәкилләре, намаз укучылар белән аралашып, акциянең максаты хакында сөйләделәр.**




"Мин Пәйгамбәребезне яратам" акциясе Татарстан мөселманнарын берләштереп, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата хөрмәт һәм ярату хисен күрсәтү максатыннын оештырылды. "Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кебек мәрхәмәтле булып һәм башкаларны хөрмәт итеп, яратып ислам кыйммәтләрен җиткерергә телибез. Бу акция Коръәндә язылган, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәткән ислам кыйммәтләрен, идеалларын тагын бер мәртәбә искә төшерә. Шушы рәвешле Мәүлид ае уңаеннан оештырылган чараларга йомгак та ясыйбыз. Мөселманнар һәрвакыт начарлыкка яхшылык белән җавап биргәннәр, яхшылыкка чакырганнар. Бүген без дә изге гамәлләргә өндибез, мәрхәмәтле булырга дәшәбез", - диде Рөстәм хәзрәт Батыр.





Илфар хәзрәт: "Һәркайсыбызга Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлын белү, аның гамәлләрен өйрәнү кирәк. Без, мөселманнар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышына үрнәк буларак карыйбыз һәм явызлыкка да яхшылык белән җавап кайтарырга тырышабыз. Бу чараны үткәрүнең максаты - Аллаһка инанучыларның күңелләрендәге Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата булган мәхәббәт хисләрен күрсәтү, аның тормышын өйрәнергә сәбәпче булыр дип тә өметләнәбез", - дип сөйләде.



Билгеле булганча, түштамгаларның рәсемнәре иң башта интернет кырында таратылды. Күп сандагы мөселманнар әлеге рәсемнәрне социаль челтәрләрдәге шәхси битләренә урнаштырдылар. Шулай итеп, "Мин Пәйгамбәребезне яратам" дигән язулы рәсем киң таралыш алды.

Нәзарәт тарафыннан түштамгалар яшь мөселманнар катнашында үткәрелүче төрле чараларда да таратылды. 30 гыйнварда исә ул Татарстанның төрле шәһәрләрендә күпләп өләшенде.






*Айзирәк ГӘРӘЕВА*

# Пәйгамбәребезгә багышлап уздырылган конкурста җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды

**Мәүлид бәйрәме уңаеннан "Дин вә мәгыйшәт"нең ноябрь санында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланган шигырьләр конкурсы, ә "Умма" газетасында викторина игълан иткән идек.**




Ике ай дәвамында укучыларыбыздан викторина сорауларына җаваплар һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышланган шигырьләр алдык. Викторинага нәтиҗә ясау катлаулы түгел - кем дөрес җавап бирә - шул җиңә. Ә менә бер кочак шигырь арасыннан иң-иңнәрен сайлап алу җиңелләрдән булмады. Газетабызның узган санында җиңүчеләрнең исемнәрен игълан иткән идек инде. Шуларның кайберләрен Диния нәзарәтенә кунакка дәштек. ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге белгече Тимергали хәзрәт Юлдашев, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында сөйләгәннән соң, шагыйрьләр Рифат Сәлах һәм Нурфия Халиковага Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм "Хузур" нәшрият йорты тарафыннан әзерләнгән бүләкләрне тапшырды, аларга иҗат уңышлары теләде.

Конкурста уңышлы шигырьләре белән катнашкан барлык шагыйрьләргә, шулай ук "Умма" газетасында үткәрелгән викторина сорауларына дөрес җаваплар җибәргән укучыларыбызга да ихлас котлауларыбызны һәм истәлек бүләкләребезне юллыйбыз.

# ТАТАРСТАН МӨФТИЯТЕ ТАТАР ШӘМАИЛЛӘРЕ КОНКУРСЫН ИГЪЛАН ИТӘ

**Шәмаил - татар халкы рухи мирасының аерылгысыз өлеше саналучы борынгы мөселман каллиграфия сәнгате. Шәмаил - буыннардан буыннарга күчкән күңел догасы. Изге Коръән аятьләре, сүрәләр язылган шәмаилләр элек-электән татар өйләрен бизәп, нур биреп торган. Безнең халык еш кына шәмаилләрне пыялага, төсле фольгалар кулланып һәм милли бизәкләр төшереп ясаган.**





Шәмаилләргә бәйле традицияләрне саклау һәм ныгыту максатыннан конкурс уздырыла. Татар шәмаиле конкурсы ТР МДН оештырган "Минем өемнең шәмаиле" республика акциясе кысаларында үткәрелә.

**КОНКУРС НОМИНАЦИЯЛӘРЕ:**

Профессиональ каллиграфия. Әлеге номинациягә пыялага ясалган классик татар шәмаилләре кабул ителә. Җиңүчеләргә премияләр каралган (20 мең сум, 15 мең сум, 10 мең сум). Иң яхшы эшләр акциянең махсус каталогына кертеләчәк. Эшләр А4 (210 мм-297мм) - А2 (420мм-594мм) форматында кабул ителә. Өстенлек стандарт форматларга бирелә (А4, А3, А2).

**Һәвәскәр каллиграфия.** Әлеге номинациядә автор үзе теләгән техниканы кулланып ясаган шамаилләр кабул ителә. Җиңүчеләргә премияләр каралган (7 мең сум, 5 мең сум, 3 мең сум). Иң яхшы эшләр акциянең махсус каталогына кертеләчәк.

**Балалар иҗаты.** Катнашучыларны һәм җиңүчеләрне истәлек бүләкләре, грамоталар, рәхмәт хатлары көтә. Иң яхшы эшләр акциянең махсус каталогына кертелергә мөмкин.

**Гаилә ядкаре.** Әлеге номинациягә гаилә шәмаилләре фотолары кабул ителә. Иң үзенчәлекле эшләр акциянең махсус каталогына кертеләчәк һәм шәмаилләр күргәзмәсендә урын алачак. Гаилә шәмаилләрен саклаучыларга истәлек бүләкләре тапшырыла. Шулай ук аларга шәмаилләрендәге язулар укып күрсәтеләчәк һәм тәрҗемә ителәчәк.



Конкурста катнашкан иң яхшы шәмаилләр күргәзмәсе Кол Шәриф мәчетендә 15 майдан алып 15 июльгә кадәр уздырылачак. Конкурска килгән эшләрне профессиональ жюри һәм 15-21 май көннәрендә үткәреләчәк тавыш бирүдә катнашучылар бәяли. Җиңүчеләр 21 майда - Идел буе Болгарында Исламны кабул итү көнендә игълан ителә. Җиңүчеләр "Яңа гасыр" телеканалының татар шәмаилләре сәнгатенә багышланган тапшыруларында катнаша ала.

Конкурс эшләре фотографияләрен 25 апрельгә кадәр info@dumrt.ru электрон почтасына җибәрергә кирәк. Фотографияне җибәргәндә авторның тулы исеме, номинация һәм иҗат эше исеме күрсәтелергә һәм катнашучы хакында кыскача мәгълүмат язылган булырга тиеш.




Конкурсны оештыручылар: Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, "Татар сәнгате һәм мәдәнияте (Татар шәмаилләре галереясы) клубы" иҗтимагый оешмасы, "Казан кремле" музей-тыюлыгының Ислам мәдәнияте музее.

**Мәгълүмати партнерлар: "Татмедиа", "Яңа гасыр", "Хузур" нәшрият йорты.**



# ЧЫН ИРЛӘР ЧЫН АНАЛАРДАН ТУА

**Ватанны саклаучылар көненә карата бүгенге җәмгыятьтә төрле фикерләр яши. Уйлап чыгарылган дата, җаһилият чорыннан калган бәйрәм, диләр. Кайберләре хәтта "ватан" төшенчәсе белән бәйле булганга кабул итә алмый. Аларга җавап итеп, болай диясе килә: "Без монда туган, монда үскән, кендек каныбыз шушы җиргә тамган, бабайларыбыз шушы ил өчен башларын салган. Безнең яратырлык, сакларлык бүтән ватаныбыз юк!". ... Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә "Чын ирләр чын аналардан туа" дип исемләнгән сөйләшү дә очраклы гына рәвештә нәкъ менә 23 нче февраль көненә туры китереп оештырылмагандыр. Әмма анда сүз "ватан" төшенчәсе тирәсендә әллә ни куертылмыйча, беркемне дә битараф калдырмый торган тема - ир баланы тәрбияләүгә багышланды. Мәсьәләне төрле яклап яктыртуны күздә тотып, Диния нәзарәтенең яшьләр бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимерова әлеге очрашуга дин әһелләрен дә, педагогларны, психологларны да чакырган иде. Тәрбиянең психологик нечкәлекләре, шәригатьтән тайпылмыйча, балага дөрес тәрбия бирү серләре турында педагогика фәннәре кандидаты, Россия ислам институты мөгаллимәсе Гөлназ Галәвиева бәян итте. Ир бала тәрбияләүнең педагогик аспектлары Зөбәйдә ханым Низамова тарафыннан ачылды. Баш казый, хөрмәтле дин әһеле Җәлил хәзрәт Фазлыев исә, шәригать кануннарына таянып һәм үз тәҗрибәсеннән чыгып, ир бала тәрбияләүнең, гаиләне һәм милләтебезне саклап калуның үзе инанган ысулларын аңлатты; кунакларның һәм тыңлаучыларның күп санлы сорауларына җаваплар бирде.**





**ҖӘЛИЛ ФАЗЛЫЕВ:**

- Биредә утыручы егетләрне Ватанны саклаучылар көне белән тәбрик итәсем килә. Менә кайберәүләр, андый бәйрәм юк ул, дип әйтәләр инде. Акыллы кешеләр: "Ә моңа дәлил бармы?" - дип тә сорыйлар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисен китерәм: "Һәр имамның артына басып намаз уку - ваҗиб, хәтта ул имам бозык булса да. Бер кеше үлгән булса, аңа җеназа уку - ваҗиб, хәтта ул кеше зур гөнаһлар кылган булса да. Илне сакларга бару - ваҗиб, хәтта патша кәфер булса да". Икенчесе: "Ватанны сөю - иманнан". Монысын зәгыйфь хәдис дип әйтүчеләр дә бар. Кешене тәрбияләүдә зәгыйфь хәдисләрне файдаланырга ярый.

Бүген бала хокукы дигән әйбер бик киң таралган, бигрәк тә Көнбатыш илләрендә. Балага кычкырырга ярамый, сугарга ярамый, хәтта мәктәп бакчасында яшелчәләргә су сибәргә кушарга да ярамый... Ә бит ул баланың хокуклары белән бергә вазыйфалары да бар. Башта Аллаһы тәгаләә каршында, аннары әти-әни, туганнары, милләте, ватаны каршында. Аларны, менә бу - безнең ватаныбыз, без аны сакларга, аңа хезмәт итәргә тиешбез, дип тәрбияләмәсәк, тәрбиябез мөкәммәл булмас, дип уйлыйм.

"Мең дә бер хәдис" җыентыгыннан: **"Бер сәгать постта тору - мең ай нәфел гыйбадәтеннән хәерлерәк"**, - дигәнен таптым. Бүген безнең арада армия сафларында 2-3 ел хезмәт иткән кешеләр яши, алар ничә сәгать постта торды икән? Тәһәҗҗүдтә торабыз, нәфел намазлары укыйбыз, үзебезчә саваплы буласыбыз килә инде, әмма нәфелләрне үтә кенә постта торган савапларны алабыз микән? Яшь чагында армия хезмәтен үтәп кайткан ирләрне, җаһилияттә яшәдегез, бернәрсә эшләмәдегез, дип сүгәргә ярамабыз. Әмма аларның күңелләрен тибрәтеп: "Сез шундый савапка ия булгансыз бит, инде хәзер саваплы гамәлләрегезне тагы да арттырыгыз", - дип нәсыйхәт итсәк, котласак, берни дә югалтмабыз, иншә Аллаһ.

Чын ирләр чын аналардан туа, дисез. Кайдан белеп була - чын анамы ул-юкмы? Менә тагын ике атнадан 8 нче Март бәйрәме җитә, бөтен кеше аяктан яза инде чабып. Мин хатын-кызларны котламаска кирәк димим, әмма хатын-кызы булып туган өчен генә зурлауны дөрес дип санамыйм. Менә ноябрь ахырында Әниләр бәйрәме бар, ул ничектер бик тыйнак үтә безнең. Әни булсын өчен кыз кеше әле кияүгә чыгып, ким дигәндә, бер бала табарга тиеш бит...

Чын әни нинди булырга тиеш - башта шуннан башлыйк әле. Бүген безнең хатын-кызларыбыз өчен беренче чиратта уку мөһим, аннары акчалы эш, аннары карьера. Аннары вакыт калса, бәлки, берәр бәби табармын әле, ди ул. Кайсы кияүгә чыга алмый кала шунда, кайсының вакыт үтеп киткән була...

Бүгенге җәмгыятьтә шулай ук дөрес булмаган тагын бер күренеш бар. Берәр очрашуга чакыралар да, менә бу галимә хатын-кыз, менә шагыйрә хатын-кыз, менә җырчы хатын-кыз, менә депутат хатын-кыз, дип аны түргә утыртып куялар... Госсоветта йоклап утыру өчен хатын-кыз булу мәҗбүри түгел бит ул, аны ирләр дә эшли ала. Мин бу эшләрне хатын-кыз эшләмәсен дип әйтмим, әмма аның беренче вазыйфасы - бәби табып тәрбияләү, ул башта үз эшен эшләсен. **Бүген, милләтне ничек саклап калырга, дип әллә нинди чаралар, форумнар уздыралар. Моның өчен ике генә әйбер кирәк: бөтен татар хатыны татарча сөйләшә торган ким дигәндә 3 бала үстерергә тиеш; шул балалар ун яшьтән намазны яратып, ихластан укый торган булырга тиеш. Милли-дини-демографик проблема шуның белән чишелеп бетә!** Бүген һәр биш хатын-кызның берсе бәби таба алмый. Ике генә бала табып без милләтне алга таба алып бара алмыйбыз. Өч бала алып кайтмаган икән, ничу аны президиумга утыртып, профессиясе өчен мактарга!

Һәм икенчесе - ир баланы ничек тәрбияләргә? Хатын-кыз эш дип карьера дип йөреп бөтен тормыш йөген үз өстенә алды. Мин эшләмәсәм тормыш бармый, ди ул. Шулай итеп әрәмтамак ирләр тәрбияли, уларын ялкаулыкка өйрәтә. Малай күреп ята бит - бөтен тормышны әнисе тарта, акчаны әни таба. Ә акчаны кем таба - соңгы сүзне шул әйтә, шулай бит инде. Хәзер сорау туар: хатын-кыз эшләмәсә тормыш барырмы? Бөтен Көньяк халыкларында тормышны ир өстерәп бара бит, ә без булмый дибез.

**- Ялгыз бала үстерүче хатыннар бик күп хәзер. Аларга нишләргә?**

- Без бүген ире була торып, үз өстенә ир кеше вазыйфасын алган хатын-кызларны тәнкыйтьләдек. Тол хатыннарга килгәндә, толлык ике төрле булырга мөмкин. Ире вафат була, менә сугыш чорында безнең әбиләр ирсез килеш бишалты баланы аякка бастырганнар. Берсе дә баласын ташламаган, берсе дә үз-үзенә кул салмаган. Аллаһы тәгалә аларга ныклык һәм улын чын ир-егет итеп тәрбияләргә мөмкинлек биргән, чөнки ул балалар аз гына кул астына керә башлау белән бүтән кешенең ирләре эшләгән эшне эшли башлаганнар. Әгәр син баланың, менә әтиегез булмагач, сиңа эшләргә туры килә инде, дип эштән куркытмыйча үстерәсең икән - була ул. **"Сәбәпсез талак сорап аерылган хатын җәннәтнең исен дә сизмәс"**, - ди. Әгәр ирнең исен ошатмыйча, я анасын яратмыйм, дип кенә гаиләңнән киткәнсең икән, монда инде башкача килеп чыгарга мөмкин. Аннары ялгыз ана, улым әтиле кешедән ким булмасын, дип әй чаба, әй чаба инде ул, тик барып чыкмый. **Улым кешедән ким булмасын димәскә, кеше булсын, дип әйтергә кирәк шул.**

**Ә гаиләне саклый торган иң төп механизм шәригатьтә беләсезме нәрсә? Мәһәр.** Гарәпләрдә ул 20-30 мең доллар чамасы. Шуның хәтле мәһәре булмаган егет өйләнә алмый. Алар ни өчен килеп безнең кызларны алалар. Безнең кызлар әйбәт булган өчен түгел - буш булган өчен. Мәһәр тупламасам, өйләнә алмыйм, дип ул туганнан мал табарга омтыла. Менә бу мәһәрнең ир кешене тәрбияләүдәге роле. Ул ничек тә һөнәр үзләштерергә, эшләргә, әрәм-шәрәм итмәскә өйрәнә. Мәһәргә без бик салкын карыйбыз, егеткә авырлык китермик инде, дибез. **Никах вакытында чын мәһәр дә бирә алмаган кеше киләчәктә синең кызыңны, оныкларыңны ничек карар? Гаиләсен ничек алып барыр?** Гарәпләр мәһәрнең бер өлешен никахта, бер өлешен ун ел эчендә, калганын аерган очракта бирә. Менә ул, чыгып кит, күземә күренмә дип әйтерме, кызулыгы белән 3 тапкыр талак кычкырырмы хатынга зур байлык тоттырып чыгарып җибәрәсе булгач? Безгә дә бу механизмнан файдалана башларга кирәк.

**- Хәзрәт, Сез үз уларыгызны ничек тәрбияләдегез?**

- Мин эшкә өйрәтеп үстердем. Абзар тутырып мал-туар асрадык. Абзар җыештырырга, китап укырга куша идем. Ничек Мөхәммәт Мәһдиевне укымаска мөмкин инде? Кайткач эчтәлеген сорыйм, дип китәм. Олысы укырга бик яратмый, кечкенәсе мәктәпкә кергәнче үк романнар укый иде. Булаты: "Алмаз, синең өчен абзарны үзем җыештырам, теге китапның эчтәлеген миңа сөйләрсең инде", - дип әйтә икән. Бозауга я йөгән, я казык кирәк булса, малайларга, барыгыз, тимерчедән ясатып алып кайтыгыз, дим. Әниләре: "Син бит экономист кеше, телефоннан шалтыратып әйтсәң, хәзер эшләп бирәләр инде аны", - ди. Мин шалтыратсам, китереп тә бирергә мөмкиннәр. Ә монда малай бара, кешесен таба, сөйләшә, эшләтә, аны күтәреп алып кайта... Аннары мин һәрвакытта аларның кеше белән аралашуын хупладым, бервакытта да: "Клубка чыкмагыз, киногa бармагыз", - дип өйрәтмәдем. Имам Газзәли: "Изгелек ул кешеләрдән качу түгел, син кешеләр арасында йөр, тик алар эшләгән әшәкелекне эшләмә", - дигән.

*Нәүбәһар КӘБИРОВА*
язып алды

# ХАТЫНЫ ҖӘННӘТЛЕ БУЛСЫН ӨЧЕН ИРНЕҢ БЕР СҮЗЕ ҖИТӘ

**Бүгенге вәгазьдә сүз исламда хатын-кызларның хокуклары турында барачак. "Ни өчен мәчеткә йөрмисең?", "Ни өчен намаз укымыйсың?"- дигәнгә үзләрен мөселман санаучы милләттәшләребез еш кына сорауга каршы сорау белән җавап бирә. Гадәттә алар ислам дине турында күп нәрсәне белми булып чыга.**



Менә минем дустыма өлкән яшьтәге, укымышлы бер ханым үзенең намазга басмавын болай дип аңлаткан: "Ислам хатын-кызларны түбәнсетә, шуңа күрә дингә килә алмыйм. Мөселманнар хаҗга барып, Ибраһим пәйгамбәрнең аяк эзләренә табына, ә бит ул үзенең балалы хатынын чүлдә ташлап калдырган".

Әйе, исламнан ерак кешеләр мөселманнарны Кәгъбәгә табына, кара ташка, пәйгамбәрнең аяк эзләренә (Ибраһим пәйгамбәрнең Кәгъбәне төзегәндә басып торган таштагы аяк эзләре) табына, дип уйларга мөмкин. Юк, без бары тик Аллаһы субхәәнәһү вә тәгаләгә генә табынабыз! Аның кушуы буенча, Кәгъбә тарафына карап гыйбадәт кылабыз. Бу хакта Изге Коръәндә болай диелә: "Чөнки Мөхәммәд галәйһиссәлләм Мәдинәгә күчкәч, сигез ай мәсҗид Әкъсага юнәлеп намаз укыдылар. Соңыннан Аллаһыдан әмер булды, мәсҗид Хәрамга юнәлеп укырга" ("Бәкара", 142,144 нче аятьләр).

Ибраһим галәйһиссәлләмнең хатынын һәм улын чүлдә калдырып китү тарихына әйләнеп кайтсак, чыннан да, бу Коръәндә телгә алынган вакыйга. Хатыны Һаҗәр аның пәйгамбәрлегенә, аларны болай гына чүлдә ташлап китә алмаслыгына ышана һәм аякларына сарылып: "Син үзең шулай карар кылдыңмы, әллә бу Аллаһының әмереме?"- дип сорый. Ибраһим галәйһиссәлләм күз яшьләре аша: "Аллаһ әмере", - ди. Чынлап та, кабул итәр өчен авыр мәгълүмат: сөекле хатынының, көтеп алган газиз баласының сусыз, ризыксыз чүлдә ничек калдырып китмәк кирәк? Ләкин пәйгамбәрләр катнашындагы вакыйгаларда аерым бер мәгънә бар. Еш кына аларның ни өчен шулай эшләгәнлекләрен гади кешегә аңлавы авыр.

Әйдәгез, Муса галәйһиссәлләм белән булган очракларны искә төшерик әле. Аллаһы тәгалә үзен бу дөньяда барын да белүче санаган Муса галәйһиссәлләмнең дә хакыйкатькә күзләрен ача. Ул аларны Хозыр галәйһиссәлләм белән сәфәргә чыгара. Юлда Хозыр эшләгәннәр Муса галәйһиссәлләмнең акылына һич кенә дә сыймый. Ни өчен ул үзләрен елга аша алып чыккан кешеләрнең көймәләрен тишә? Ни өчен бер гөнаһсыз сабыйны үтерә? Ни өчен үзләрен төн кунарга кертмәгән кешеләрнең коймаларын рәтләп йөри? Вакыты җиткәч, барысы да беленә. Бу гамәлләрдә Аллаһы Раббыбызның зирәклеге яшеренгән икән. Иртән килеп, ярдагы көймәләрне урлап киткәннәр, тегеләр тишек көймә генә калган, димәк, балыкчы көймәсен ямап балык тота алачак, гаиләсе тук булачак. Төн кунарга кертмәүче кешеләр - ятимнәрнең караучылары, ә ишелгән койма астында бу балаларга тиешле мирас ята икән. Теге яхшы ата-анадан туган сабый исә, бик начар кеше булып үсәргә тиеш булган. Боларны Үзенең зирәклеге белән бары Аллаһы тәгалә генә белә.

Шулай итеп, Раббыбыз Ибраһим галәйһиссәлләмгә хатыны белән улы Исмәгыйльне чүлдә калдырырга боерса да, Ул аларны Үз рәхмәтеннән ташламый. Соңыннан Исмәгыйль галәйһиссәлләм нәселеннән Рәсүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөньяга туа. Күрдегезме, бу эш нинди олы максат өчен эшләнгән! Һаҗәрның, баласына су эзләп, Сафа белән Мәрва таулары арасында йөгереп йөрүләрен, шул урында – Исмәгыйль галәйһиссәлләмнең аяк очында зәмзәм суы чыгуын, аның шул суны азык-төлеккә алыштыруын, бу урында юлчылар туктый башлавын, әкренләп Мәккә шәһәре калкып чыгуын без инде тарихтан беләбез.

Ханымның тагын бер соравы – шаһитлык мәсьәләсенә кагыла. "Шаһитлык иткәндә бер ир-ат урынына ике хатын-кыз тиеш, диелгән. Бу хатын-кызны түбәнсетү түгелмени?" – ди ул. Шәригатьтә шаһитлык мәсьәләсенә бик зур игътибар бирелә, чөнки никах укытканда, нинди дә булса җинаять эшен ачканда кеше язмышы хәл ителә бит. Аллаһы субхәәнәһү вә тәгалә ирләрне һәм хатын-кызларны төрле сыйфатта яралткан. Без – ирләр көтелмәгән хәл килеп чыкканда хисләргә ирек куймыйча уйлыйбыз, анализлыйбыз, аннары хәл итү юлларын карыйбыз. Ә хатын-кызлар исә башта хискә бирелә, аннары гына уйлап төшенә башлый, нәтиҗә ясый. Кеше язмышы хәл ителгәндә, әйтик, кемнәрнеңдер зина кылганын расларга кирәк булганда нәфрәтеннән ялгыш: "Әйе, мин күрдем", - дип әйтеп ташласа, тегеләргә җәза көтә бит! Бу хатын-кызны түбәнсетү түгел, ә Аллаһының аны ялган шаһитлыктан, гөнаһтан саклавы. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мигъраҗдан кайткач, җәһәннәмдә күбесенчә хатын-кызлар булуы турындагы хәдисен искә төшерегез. Яралтучыбыз безнең өчен нәрсә яхшы, ә нәрсә яман булуын яхшырак белә! Калган барлык очракларда да ир-атлар белән хатын-кызлар бер үк тавышка ия.

Мирас бүлгәндә ир балага аның ике өлеше, ә кыз балага бер өлеше тиеш булу да, бер карасаң, гаделсезлек кебек инде. Моның да асылында тирән мәгънә ята. Мирастан ике өлеш алган бу малай үз гаиләсен корырга, хатынын, балаларын кайгыртырга тиеш. Ә кыз бала кияүгә чыга, аны ире карый. Мирастан өлешенә тигән байлык та – аның фәкать үзенеке генә, беркем белән дә бүлешәсе юк. Бу – Аллаһының гадел кануны!

Пәйгамбәребез саләллаһу галәйһи вә сәлләм килгәнче хатын-кызларның берниндидә хокуклары булмаган. "Алга киткән" Европа галимнәре әле моннан берничә гасыр элек кенә: "Хатын-кыз – кешеме?" - дигән сорауга бәхәсләр алып барганнар. Ислам хатын-кызларны биек баскычка күтәрде. Мөселман ир хатынын ашатырга, киендерергә, аны кайгыртырга тиеш. Хәтта бала табып, аны имезүдән баш тартса да, ир хатынын мәҗбүр итә алмый, баласы өчен сөт анасы табарга тиеш була. Хатын-кызның өйне җыештырмаска, ашарга пешермәскә дә хакы бар. Эшләмим, ун эштә эшләп булса да гаиләне үзең тәэмин ит, дисә дә - ул хаклы була. Ә инде эшли икән, хезмәт хакын бары үзенә генә тота ала.

Яулык, кием мәсьәләсендә сүз чыкса, еш кына безне хатыннарыбызны төренеп йөрергә мәҗбүр итүдә гаеплиләр, хокукларын кысабыз, янәсе. Ә кыска итәк кигән кыз баланы урамда теләсә кем күзләргә, бер почмакка кысарга да мөмкин – бу алар өчен нормаль күренеш! Әгәр хатын-кыз гаурәтен чит ирләргә күрсәтеп йөрергә, авыр эштә чиләнергә "хокуклы" икән – безгә андый хокук кирәкми. Бу берниндихокук та, ирек тә түгел, бу - коллык.

Шәригатьтә хатын-кыз хокукларының тагын берсенә – мәһәргә тукталасым килә. Мәһәр - өйләнешкәндә кияү тарафыннан кәләшкә бирелә торган бүләк ул. Борынгы тарихи китаплардан никах турында укыганда мәһәр мәсьәләсенә дә тап булдым. Безнең әбиләр мәһәргә беләсезме нәрсә сораганнар? 5 сыер! Хәзер сыер хакын 40 мең дип алсак, әбиләребезнең мәһәре уртача 200 мең сумлык булган. Кәләшегез алтын йөзек янына беләзеген дә сораса, күпсенмәгез, егетләр, аларның моңа хакы бар.

Никах мәсьәләсендә төрле низаглар килеп чыкмасын өчен бүгенге көндә Казыйлар шурасы никах килешүе проекты өстендә эшли. Юридик көчкә ия булачак әлеге документта хатын-кыз, мәһәргә шуны бирәсең, икенче хатын алмыйсың, дип үзенең шартларын яза алачак. Бу да хатын-кызларның хокукларын кайгыртып эшләнә.

Ә менә ир-ат, өйләнгәч миңа иртәнге ашка бәлеш, төшке ашка сарык итеннән шулпа әзерләрсең, дип үз таләпләрен куя алмый, чөнки аның моңа хакы юк.

Бүгенге заман хатын-кызлары - сәясәтчеләр дә, җитәкчеләр дә, җәмәгать эшлеклеләре дә. Дөрес, Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм заманында да андый актив хатын-кызлар булган ул. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең беренче хатыны Хәдичә, мәсәлән, сәүдә белән шөгыльләнгән. Әмма никадәр актив эшчәнлек алып барсалар да, ирләре һәрвакыт алар янәшәсендә булган, ярдәм итеп торган. Һәм ул хатыннарның берсе дә шәригать кануннарын бозмаган. Хәзерге ханымнарга, ник намаз укымыйсың, дисәң: "Хәзрәт, мин бит җитәкче, намаз укып утырсам, эшемнән алырга мөмкиннәр", – дип җавап бирә. Элекке хатыннарда мондый курку булмаган, алар Аллаһы Раббыбыз кушканнарны үтәмәүдән генә курыккан.

Аллаһы субхәәнәһү вә тәгалә хатын-кызга бик күп хокуклар биргән һәм бер вазыйфаны – гаилә учагын саклауны йөкләгән. Рабыбыз ни өчен Адәмне һәм Һәваны яралткан, дип уйлаганыгыз бармы? Бер-берсендә тынычлык тапсыннар өчен, ир-ат арып-талып өенә кайткач, хатыны янында, гаиләсендә тынычлык тапсын өчен. Ире бу дөньядан китеп барганда, мин синнән канәгать, дисә ул хатын - җәннәтле. Әйе, бүгенге заманда бизнеста, сәясәттә зур уңышларга ирешкән хатын-кызлар бар. Әмма ирең синең янында тынычлык таба алмый икән, ул бизнесың, карьераң нәрсәгә хәҗәт?

**Рөстәм ХӘЙРУЛЛИН,**
**мөфти урынбасары**

*Кеше язмышы хәл ителгәндә, әйтик, кемнәрнеңдер зина кылганын расларга кирәк булганда нәфрәтеннән ялгыш: "Әйе, мин күрдем", - дип әйтеп ташласа, тегеләрне җәза көтә бит! Бу хатын-кызны түбәнсетү түгел, ә Аллаһының аны ялган шаһитлыктан, гөнаһтан саклавы.*

*Борынгы тарихи китаплардан никах турында укыганда мәһәр мәсьәләсенә дә тап булдым. Безнең әбиләр мәһәргә беләсезме нәрсә сораганнар? 5 сыер! Хәзер сыер хакын 40 мең дип алсак, әбиләребезнең мәһәре уртача 200 мең сумлык булган.*

*Хәзерге ханымнарга, ник намаз укымыйсың, дисәң: "Хәзрәт, мин бит җитәкче, намаз укып утырсам, эшемнән алырга мөмкиннәр", - дип җавап бирә. Элекке хатыннарда мондый курку булмаган, алар Аллаһы Раббыбыз кушканнарны үтәмәүдән генә курыккан.*



*Хатларыгызны Диния нәзарәтенә (Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә naubahar67@list.ru адресы буенча җибәрә аласыз*

# Ахирәттәге мәңгелек "капитал"

***КУКМАРА** мәдрәсәсендә олылырдан тыш район үзәгендә һәм авылларда яшәүче балалар да укый. Шушы уку елында якшәмбе мәктәбе программасы буенча мәдрәсәдә 80 ләп бала дини белем ала. Яшь шәкертләребезнең нинди шартларда укыганнарын күрсәтү, нинди мөгаллимнәрдән гыйлем алганнарын, гомумән, нәрсәләр өйрәнгәннәрен җиткерү-аңлату максатыннан күптән түгел мәдрәсәдә ата-аналар җыелышы үткәрелде.*

*Дини уку йорты буларак, мәдрәсә балаларны ислам нигезләре белән таныштыруны, шулай ук әдәпле-әхлаклы булырга, тормыштагы начарлыклардан читләшергә, өлкәннәргә, бигрәк тә әти-әниләргә карата хөрмәт-илтифатлылык күрсәтергә өйрәтүне максат итеп куя. Җыелышта чыгыш ясаган мөгаллимнәр әлеге максатның ата-аналар белән берлектә тормышка ашырылырга тиешлеген ассызыклап билгеләп үттеләр. Әлбәттә, укучылар төрле, белемне дә алар төрлечә үзләштерә, әмма бала нинди генә сәләткә ия булса да, аны хәләл белән хәрамны аерырга, әти-әни, җәмгыять, ә иң мөһиме - Аллаһы тәгалә каршында җаваплылык тоярга өйрәтергә була.*

*- Бала кечкенә булган вакытта гел күз алдында, әмма үсә төшкәч, аны инде күзәтеп бетереп булмый, шуңа күрә Аллаһка ышану, Аның безне даими күзәтеп торучы илаһи Зат булуын белү бик мөһим, - дип сөйләде уку-укыту бүлеге мөдире Рифат Ибраһимов. - Балаларны тәрбияләү эшендә хәләл ризык ашату һәм вакытны дөрес файдаланырга өйрәтү иң мөһим мәсьәләләрдән санала. Еш кына күрергә туры килә: мәктәптән кайтучы укучылар яшь организм өчен зарарлы булган чипсы, кириешка яки роллтон кебек токмачны кимереп кайталар (яшүсмерләрнең кулында сыра шешәсе күрү дә хәзер инде гадәти хәлгә әверелеп бара). Чипсы белән тамак ялгап кайткан бала, өстен дә алышмыйча, ашап-эчеп тә тормыйча, компьютерга "ябырыла" һәм әти-әнисе эштән кайтканчы, сәгатьләр буе мәнсез-мәгънәсез уеннар уйный. Хәер, урта мәктәп укытучылары белдергәнчә, хәзер балаларның дәрес вакытында да телефон-планшетлар белән уйнап утырулары - гадәти күренеш. Бу исә аларның өлгерешләренә һәм, гомумән, күңел халәтенә шактый зур зыян сала...*

*Бүген ата-аналарның балаларына аеруча игътибарлы булулары сорала. Әмма күп гаиләләрдә тәрбия эше телевизор белән компьютерга һәм урамга "йөкләнеп", үзагымына куела. Кызганыч ки, хәзер ата-аналар үзләре дә телевидение-интернет йогынтысына елдан-ел күбрәк бирелә башлады. Шушы фикер белән бәйле булган кызыклы да, гыйбрәтле дә бер кыйсса искә төшерелде җыелышта. ...Әдәбият укытучысы балаларга "Минем иң зур хыялым" дигән темага инша яздыра. Кичен шул иншаларны тикшереп утырганда, укытучының игътибарын "Минем иң зур хыялым - телевизор булу" дип башлана торган инша җәлеп итә. Аны язган малай шушы теләгенә аңлатма биреп болай дигән: "Әгәр мин телевизор булсам, әти-әнием кич буе миңа карап утырырлар иде, шактый күп вакытларын миңа багышларлар иде, минем белән андый-мондый хәл килеп чыкса, "ай-вай" килерләр иде, ә ватылсам - бик кайгырырлар иде. Ә әлегә - көндез мин аларны күрмим, кичен исә - алар мине күрми".*

*Дөрестән дә, бүген замана техникасы шаукымы нәтиҗәсендә ата-аналар белән балалар арасы ерагая бара шикелле. Кая инде монда баланың күңел халәтен кайгырту: ашатып-эчертеп, өсте-башын рәтләп куя алсаң да - бик рәхмәт... Баланың рухи дөньясын баету, аны кешелекле, мәрхәмәтле, үз гамьләре өчен җаваплы булырга өйрәтү - тәрбиягә кагылышлы бик олы, әһәмиятле вазифа ул, һәм моның турында бөтенләй уйламау, әлбәттә, дөрес түгел.*

*Җыелышта чыгыш ясаган мөгаллим Айрат Шәфигуллин билгеләп үткәнчә, мәктәп тә, мәдрәсә дә, ата-аналар да, асылда, бер максат куя: бала укымышлы булсын, җәмгыятьнең лаеклы бер бәндәсе дәрәҗәсенә ирешсен. Шулай да, мәктәптә укучыларның фәнни белемнәрне яхшы үзләштерүләренә өстенлек бирелсә, ата-аналар балаларының бу тормышта үз урынын табып, яхшы урнашуларын телиләр. Мәдрәсәдә исә әхлакый тәрбия белән беррәттән тагын бер олы, үтә мөһим мәсьәлә игътибар үзәгендә тора: ул да булса - шәкертнең бу дөньяда гына түгел, ахирәттә, мәңгелек тормышта да бәхетле булуы... Бу уңайдан Айрат хәзрәт Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу гәләйһи вә сәлләмнең шундый хикмәтле сүзләрен мисал итеп китерде: "Әти-әнинең баласына биргән иң яхшы бүләге - ул күркәм тәрбиядер. Балага дөрес, яхшы тәрбия бирү - аңа бөтен дөнья байлыгын бүләк итүгә караганда да яхшырак, хәерлерәктер".*

*Ислам күзлегеннән караганда, яхшы тәрбия ул - тәүфыйклы, инсафлы булудан тыш, фарыз-вәҗибләрне, ягъни Аллаһы тәгалә безгә йөкләгән төрле бурычларны да үтәргә тырышудыр. Дөрестән дә, балаларыбыз намаз укыса, гыйбадәт, изгелек кылса, әти-әниләре өчен шушы фани дөньяда игелекле ярдәмче, ышанычлы терәк булып, мәңгелектә, ахирәттә бетмәс-төкәнмәс шатлык-сөенеч чыганагы булулары да бик ихтимал, чөнки баланың кылган догасы бу дөньядан бакыйлыкка күчкән әти-әнисе өчен аларның ахирәттәге мәңгелек "капиталы"...*

**Ришат КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе директоры**

# РӘХМӘТЛӘРЕМНЕ ЮЛЛЫЙМ

*ЭЛЕК без үскәндә, динне яшеренеп кенә тоталар иде. Әби-бабайлар без туганчы үлеп беткәнлектән, алардан догалар өйрәнеп үсәргә туры килмәде. Әтинең җиңгәсе улы армиядән кайтканчы бездә яшәде. Аның намаз укуына, дус хатыныннан килгән гарәпчә язулы хатларны укуына бик кызыга идем. Ул миңа берничә дога өйрәтеп калдырды. Авылдашларымның (Арча районы Каенсар авылы кешеләренең) корбан чалуларын, сыйныф җитәкчесе күреп орышмаса ярар иде, дип корбан ашларын авыл буенча өләшеп йөрүемне хәтерлим. Аннан әни атаклы Югары Курсада туган, анда дин көчле булгандыр, аның 3 абыйсы да намаз укый иде. Аларга кунакка баргач, яланаяк, яланбаш йөрергә ярамый иде.*

*Аллаһы тәгалә, теләгәне тормышка ашсын, гарәп язуын өйрәнсен, дигәндер инде, мин Арча педучилищесыннан соң Казанда ул вакытта бердәнбер булган университетның филология факультетында укыдым. Безгә көчле укытучылар белем бирде, мин аларга бик рәхмәтлемен. Кураторыбыз булган Мөхәммәт Мәһдиев исемен искә алу да күп нәрсә турында сөйли. Урыны оҗмахта булсын, аның дәресләрен әле дә сагынам. Университетта укыганнар югалмадылар, тормышта үз урыннарын таптылар, язучы булып китүчеләр дә бар.*

*Менә шунда - университетта укыганда, гарәп хәрефләрен өйрәнү курслары керде. Җәмил абый Зәйнуллин кыска гына вакыт эчендә безгә бу фәнне яраттыра алды. Аннан 90 нчы елларда, 9 нчы сыйныф әдәбиятында "Коръән һәм татар әдәбияты" дигән тема бар иде. Анда Коръән турында кызыксындырырлык итеп язылган, хәреф өйрәтү дә каралган иде, мин бу теманы укучыларыма бик яратып укыттым. Әмма Коръән укый белми идем әле ул вакытта. Аннан, районда "Яшел Үзән" газетасы оештырган конкурста урын алгач, миңа редакция намазлык бүләк итте. Бүләгемә бик озак карап утырганым истә. Намазны Рәшидә апа Исхакыйның намаз өйрәтү китабыннан карап, үзлектән өйрәндем, догалар ятлый башладым. Аңа да Аллаһның рәхмәтләре ирешсен, бик тәфсилләп өйрәткән.*

*Дүрт ел элек шәһәрләрдән дә уздырып эшли торган мәктәбебезне ябып куйдылар... Башта бик кайгырган идем мәктәп беткәнгә, эшсез калдык бит. Пенсия яшенә җитсәм дә, кечкенә кызымны укытып бетерәсе бар, кредит түлисе бар. Рәхмәт киявем Илдус белән кызым Гүзәлгә, алар, Казанда эшләрсен, дип үзләрендә торырга чакырдылар. Хәзер оныкларымның ничек үсүләрен күреп куанам.*

*Минем бәхеткә, йортыбыздан ерак түгел Гаилә мәчете ачылды һәм миңа шунда уку насыйп булды. Аллаһка мең шөкер, безне бик таләпчән дә, тирән белемле Хәмдия абыстай укыта. Шушы ике ел эчендә ислам дине турында, пәйгамбәрләр, намаз, дин галимнәре турында күпме мәгълүмат алдык, яттан күпме сүрә өйрәндек, Коръән уку серләренә дә төшенә барабыз. Курсташларым Тәнзилә, Рузалия, Зөлфия, Данияләр дә бик кешелекле, ярдәмчел булып чыктылар. Бик тырышлар, сөенеп укыйлар. Әкренләп күптән хыялланганыбыз чынга аша, хәзер ашларда ни укыганнары да аңлашыла, Коръәнне аңлап укый башладык... Шушы Гаилә мәчетен төзеткән һәм төзегән кешеләргә, бүген уку өчен безгә шартлар тудырган җитәкчеләргә, һәрчак хәлебезне белешеп торган мәчетнең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллинга, абыстаебыз Хәмдия ханымга Аллаһның рәхмәтләре булсын. Шушы мәчетне җыештырган, миченә яккан, каравыл торган, хезмәте кергән һәммә кешегә, бергә укыган төркемдәшләргә бәрәкәтле тормыш, зур куанычлар, чиксез бәхетләр, сәламәтлек, озын гомерләр бирсен. Балаларыбызга, оныкларыбызга да шушында белем алуларны насыйп ит, я Раббым!*

**Сөмбелә АБДУЛЛИНА,**
**Яшел Үзән**

## Яңа сәхифәбез – "Фронтовик хатлары"

***Хөрмәтле укучыларыбыз! Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан "Дин вә мәгыйшәт" газетасы "Фронтовик хатлары" дигән яңа сәхифә ачып җибәрә. Бәлки сездә дә әбиләрегез гомер буе сандык төпләрендә кадерләп саклаган, сагынудан күз яшьләренә манчылган хатлар сакланадыр. Әйдәгез, бергәләп шул хатларны укып, хәтер яңартыйк әле. Җиңүчеләрне беркемнең дә онытырга хакы юк! Хатларыгызны naubahar67@list.ru адресына җибәрегез. Күбрәк кеше ишетсен өчен аларны "Азан" радиосында да яңгырату, radioazan.ru һәм islam-today.ru сайтларына урнаштыру мөмкинлеге дә бар.***



*Хатларыгызны Диния нәзарәтенә(Лобачевский ур., 6 нчы йорт)*
*яисә naubahar67@list.ru адресы буенча җибәрә аласыз*

# "БИСМИЛЛӘҺ"НЕҢ ФАЗЫЙЛӘТЕ

Әссәләәмү галәйкүм, мөхтәрәм "Дин вә Мәгыйшәт" газетасы хезмәткәрләре! Гамәлегездә вә тормышыгызда сезләргә Аллаһы тәгалә хәерле ярдәмнәрен бирсен. Сезнең "Дин вә мәгыйшәт" газетасы милләттәшләребез арасында динебезне ныгыту юлында күркәм эш башкара. Машаллаһ! Биредә басылган һәр язма аны аңлаучылар өчен гыйбрәтле һәм файдалы.

Мин - Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасымын. Шактый сандагы дөньяви әсәрләрдән тыш туксанынчы еллардан башлап ислам поэзиясен популярлаштыру юнәлешендә дә тырышлык күрсәтәм. "Иман" нәшриятында Вәлиулла хәзрәт Ягъкуп хәерхаһлыгында "Зур дога: исме әгъзам" (2001), "Олуг китап балкышы" (2005) исемендә сонетлар китаплары басылып чыкты. 2007 елда шул ук нәшриятта 100 тезмә вәгазьләрдән торган "Нурҗәлал" исемле китабым дөнья күрде. 2008 елда шигырьләр, сонетлар һәм кайбер поэмаларын эченә алган "Кыйбла" исемле китап, "Рәгъбәт", 2011 елда "Ихласлык" һәм "Нәзакәт" исемле китаплар басылды. 2012 елда "Бакый аһәң" һәм "Игътикад" , 2013 елда "Истикамәт" дип исемләнгән китапларым дөнья күрде. Мәскәүдә Россия Мөфтиләр Шурасы һәм "Өмет" мәдәни - мәгариф фонды тарафыннан Рәсүлебез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәүлиденә багышлап оештырыла торган "Дөньяга рәхмәт йөзеннән җибәрелгән Мөхәммәд Пәйгамбәр(саллаллаһу галәйһи вә сәлләм)" дигән Бөтенроссия шигырь бәйгеләрендә ел саен катнашып, мактаулы урыннар яуладым.

Газетагызның даими укучысы буларак, сезнең хөкемгә бер әсәр җибәрәм. Сезгә эчкерсез ихтирам белән Чүпрәледән

**Рафаил СИРАҖИ**

*"Бисмилләһи" - көчле корал мөэминнәрнең рухында.*
*Гадәт итсәң, һәрдаим дә, бу сүрәне укырга,*
*Һәр гамәл башлангычына ошбу сүздән керешсәң -*
*Раббың сине буш калдырмас "рәхмәт" дигән өлештән.*
*Бу олуг, хикмәтле сүзнең мәгънәсенә төшенү -*
*Изгелек юлына кертер һәр иманлы кешене.*
*Бу дөньяны яманлыкка этәрүче көчләр бар.*
*Алар - шайтан. Шул ләгыйньгә ияручe кешеләр бар.*
*Бу сүзләрем шушы хакта. Колак сал, и, кардәшем.*
*Теләгем шул: яманлыкны фаш итәм, дип, көрәшү!*

***

*Очраштылар ике шайтан иске мунча янында.*
*Берсе симез, берсе ябык - чак тора аягында.*
*Зәңгәрләнгән тиресендә чак таралмый сөяге.*
*Сулуын да, чак-чак алып, менә ниләр сөйләде:*
*-Иблис бабайның таләбен ничек үтәргә белмим...*
*Мин бетәм бугай, и, сафташ, бирмиләр миңа берни.*
*Бәдрәфләре ишегеn дә дин кушканча ачалар,*
*Алар кергән мунчадан да "безнекеләр" качалар.*
*Терлек абзарларына да "бисмилләһ" дип керәләр,*
*Чыкканда да, келәләрен шулай диеп эләләр.*
*Йорт хуҗасы - саф әхлаклы, намазын укый, кортка...*
*...Бүтән керә алмыйм инде мин ул иманлы йортка...*
*"Бисмилләһ" сүзен ишетеп, калтыранды симезе -*
*Хәрам ашап симергәнe, (хасса, нәсел үгезе)...*
*Сөйли: "Мин яшәгән йортта - рәхәтлек ташып тора.*
*Монда һәркем, ашаганда - берни әйтми утыра.*
*Һәр капкан ризыклары да керә минем карынга.*
*Мин -симерәм, үзләштерeп, өстәлдә нибарын да...*
*Бу азгыннар оясында үз итеп бездәйләрне,*
*Яшиләр, хилаф эш кылып, чөмереп хәмер-мәйне.*
*Сул кулга тотып ризыкны -мине тукландыралар.*
*Әйдә, кер, безнең " ояга", хәл алырсың бераздан.*
*Әйтербез Иблис бабайга: "Ул, аз-маз, юлдан язган..."*
*...Мин торган хәмерле йортта бик тиз сафка керерсең.*
*Ахырында, азгын йортны үзең таба белерсең..."*

***

*Әлхасыйль, юкка чыгара җен-шайтанны "бисмилләһ".*
*Бисмилләһле булса йортың - һәр җанга сафлык тула!*

# БУ РӘХМӘТЛӘРЕБЕЗ ҖӘННӘТ АЧКЫЧЛАРЫГЫЗ БУЛСЫН



Гает бәйрәмнәрендә, уку елын тәмамлау, я балалар өчен кышкы, җәйге лагерьлар ачылу уңаеннан уздырыла торган матур бәйрәмнәргә килгән саен Гадел мәчете коллективының халкыбызны бәхет-сәгадәт юлына, ныклы иманга тартудагы тырышлыкларын, ару-талу белмичә, үз мәнфәгатьләре, саулыклары-вакытлары белән исәпләшмичә эшләүләрен күреп хозурланып кайтабыз. Ә бу юлы бигрәкләр дә сокландык. Мәчетнең эчендәге үзгәрешне күреп шаккаттык: шулхәтле камиллек, күркәмлек белән үзгәртеп корганнар! Бу, әлбәттә, бистә халкының һәм мәчет коллективының бердәм тырышлыгы нәтиҗәсе.

Урамда ак дивар булып, ишелеп кар ява, күз ачкысыз буран... "Чакырган җиргә бар", - ди халкыбыз, бигрәк тә Мәүлид кебек олы бәйрәмгә. Кар ерып көч-хәл белән барып керсәк, мәчеттәге манзарага ис китте - асыл күлмәкләрен киеп, аллы-гөлле яулыкларын бәйләп өстәл тирәсен тутырып утырган кардәшләрнең йөзләреннән нурлар бөркелә. Рәхмәт яугырылары!

- Аллаһы сөбханәһү вә тәгалә Үзе дә, Аның фәрештәләре дә бүген сөекле хәбибенә салаватлар әйтер икән, - дип башлады сүзен мәчеттә уку-укыту эшләре буенча җаваплы мөгаллимә Фәния абыстай Җәләлиева мәҗлесне ачып һәм беренче сүзне имам-хатыйб Рөстәм хәзрәт Бакировка бирде. Коръән сүрәләрен укып, дога кылып, хәзрәт мөбарәк теләкләрен җиткерде, мәчеттә озак еллар буе дәресләр алып баручы тату, бердәм мөгаллимнәр коллективына рәхмәтләрен белдерде.

- Әйе, Коръән уку төркемнәребез - горурлыгыбыз, әлхәмдүлилләһ, - дип дәвам итте Фәния абыстай, - үзем укыткан, "Мөхәммәдия"не тәмамлаган укытучыларыбыз 2-3 әр класс алып баралар. Атналар буе бөтен класс бүлмәләре тулы халык, олысы-кечесе Коръән өйрәнә. Менә ике ел элек мөгаллимнәребезне дә өстәмә укыта башладык. Дин галиме Равил хәзрәт Бикбаев һәр чәршәмбе бездә ислам нигезләре, мөселманның әхлагы һәм Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы турында вәгазьләр сөйли.

Алга таба мәҗлес табибә Әлфия Һадиеваның моңлы-аһәңле, тирән эчтәлекле мөнәҗәтләре белән үрелеп барды. Һәм барыбыз бергәләп, намаздагыча куларны күкрәккә баглап, салаватлар әйттек, әйтерсең лә, күңелләребездә кояш балкышы! Быел икенче мәртәбә хаҗ кылып кайткан мөгаллимәбез Финзия олы бүләк - зәмзәм суы белән килгән. Бисмилләбезне әйтеп, зәмзәм суы эчтек.

- Мөхәммәд Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең безләрне берләштерә торган бу бәйрәме мөбарәк булсын, - диде Россиянең Мөселман хатын-кызлар берлеге рәисе Наилә абыстай Җиһаншина. - Мәчеттәге бу матурлыкны күреп шаклар каттым, танымадым хәтта. Бу тырышлыкларыгыз өчен рәхмәтләребез җәннәт ачкычы булсын. Мәчеткә нигез салган Фердинанд хәзрәтебезнең рухлары шаттыр, иншә Аллаһ. Хатыны Рәүфия ханымга да рәхмәт, ире эшен дәвам иттерүдә көчен дә, барлыгын да җәлләми. Ә эш барыбызга да җитәрлек, балаларны, яшьләрне иманлы итеп тәрбияләп үстерүдә бергәләп тырышыйк.

Җәмәгать эшлеклесе Әлмира абыстай Әдиатуллина да җыелган җәмәгатьчелекне бәйрәм уңаеннан кайнар котлап, Апаска булган сәфәре, андагы халыкның ныклы иманга тартылып яшәве хакында сөйләде.

- Районнарга күбрәк барыйк, халык белән эшләү мөһим, - диде ул. Сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәүлиден мәдәният сарайларында да үткәрәсе иде. Аның дөньядагы иң изге җанлы кеше булуын, иң камил тәрбия үрнәге булган яшәү рәвешен, кылган гамәлләрен балаларыбызга, оныкларыбызга сеңдерергә бурычлыбыз.

20 ел буе "Татар мөселман календаре"н чыгарып килүче Фәния Хуҗахмәтнең чыгышын сәгатьләр буе тыңлап туймассың. Ул әле китаплар да чыгара, матбугатта актив катнаша, афәрин, кардәшкәебез! Бу юлы да яңа китапларын - Мөхәммәд Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең чын тормышын һәм Тукаебызның ни дәрәҗәдә Аллаһы тәгаләгә табынуын яктырткан гаять көчле шигырьләре тупланмасын күтәреп килгән:

- Пәйгамбәрләр солтаны Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышын күбрәк белгән саен җанында якты нурлар арта баруын тоясың. "Өммәтем, өммәтем..." - дигән бит! Аллаһы тәгалә Коръәнне дөньяга таратучы итеп аны сайлап алган! Без аның сөннәтен ныклап өйрәнергә тиешле. Ике көн ач торыр иде, ди. Бер көнендә тәүбә итәр, икенче көнендә шөкер кылыр иде, ди. Менә бу китабым аның тормышы турындагы чын хакыйкать. Укыгыз, үрнәк алыгыз, гыйбрәтләр алыгыз. Бу бәйрәмгә чакыруыңа рәхмәт, абыстайкаем! Очрашуларыбыз дәвамлы булсын!

Үзем исә яңа гына Магнит каласыннан кайтып төшкән идем. Андагы милләттәшләребезнең дин юлындагы, милләтне, телне, гореф-гадәтләребезне саклаудагы фидакарьлекләре турында сөйләдем. Шөкер, халкыбыз иман юлында; Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтен үтәп, Изге Коръән кушканча яшәргә тырыша.

**Мөслимә ШӘФЫЙК**

# ГЫЙЗЗӘТЛЕ ТӨРЕК ШӘЙХЕЛИСЛАМНАРЫН ТЕТРӘТКӘН ШӘХЕС

**... Бәян итәсе хәбәрләребез Муса әфәнде Бигиевның 1923 елда Берлинда дөнья күргән "Ислам милләтләренә чакыру" исемле китабыннан алынды. Ике төрле сорау ихтималын фараз итәбез. Берсе: "Нигә инде һаман хатын-кыз мәсьәләсен тикшерәбез, башка эш юкмыни?" кебегрәк яңгыраса, икенчесе: "Аның фикерләрен гел халык хозурына чыгарып күрсәтерлекме соң? Кем ул Муса Бигиев?"- дигән сорау була ала.**

Әүвәл беренче сорауга җавап бирик. Исламда яшәмәсәк, киләчәктә бер милләт булып калуыбыз мөмкин түгел. Котылуыбыз, ахирәттә сәгадәтсөенечләргә ирешүебез өчен ислам шәригатенчә гомер итәргә, иманлы-тәкъвалы булырга тиешбез. Моның өчен халыкны исламга табан борырга, аның өстенлеген, камиллеген, тулылыгын күрсәтергә тиешбез. Адашкан һәм юлын таба алмаган милләттәшләребезне бабаларыбыз тоткан ислам дине белән яңадан таныштыру өчен матбугаттан да, радио-телевидениедән дә, вәгазь-нәсихәтләрдән дә, мәктәпләрдән дә файдаланып була. Әмма бар шундый бер чара - аннан да үтемле, аннан да нәтиҗәле вә уңышлы башка бер чара юктыр. Сүз - ана тәрбиясе турында. Халыкка, киләчәк буыннарыбызга динебезне аналар гына бирә ала. Исламча яшәүче хатын-кызларыбыз буыны булса, татар саны да артыр, динебез дә көчәер иде. Вокзалларда исереп аунап ятучы татар хатыннары, фәхешлек кылучы кызлар булмас иде...



Муса Җаруллаһ улы Бигиев

Гүзәл яртыбызны бозыклык, фәхешлек, сәрхушлек һәм башка шундый яманлыклардан коткарыйк дип җиң сызганып эшләр булсак, бу изге эшкә хөкүмәтебез дә, дин әһелләребез дә, матбугатыбыз да, әдипләребез дә, мәктәпләребез дә, мәдрәсәләребез дә алынырга тиеш. Әмма беренче чиратта "шәригать кысаларында изелгән татар хатыны" дигән мифны фаш итәргә кирәк... Юкмыни безнең татар кешеләре арасында бу хакта сүз йөрткәннәр? Бар, әлбәттә. Аларның берсе Муса әфәнде Бигиевтыр.

1875 елда Ростов-на-Дону шәһәрендә туган. Русский технический лицейны тәмамлаганнан соң дини белем дәрьясына кереп, әллә кайсы мөселман илләрен гизеп кайта. Камил сурәттә гарәп, фарсы, төрек, урыс телен белә. Һиндстанда яшәгән дәверендә санскрит телен өйрәнеп өлгерә. Безгә аның 200 дән артык әсәренең исеме мәгълүм. Бөек галим, публицист, милләтпәрвәр, фәкыйһ, коръәнхафиз, тел белгече. Аны ислам дөньясында беләләр. Аның фикерләре вә китаплары гыйззәтле Төркия шәйхелисламнарын тетрәткән, мисырлы гарәпләрнең мәхәббәтен-ихтирамын яулаган. Һиндстан мөселманнарына өмет биргән. Кайберәүләр аны хәтта "Бохарилардан да олуг галим" дип танудан курыкмыйлар...

*Айдар ХӘЙРЕТДИН*

# ХАТЫННАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫНА, ВАЗЫЙФАЛАРЫНА ДАИР (КАГЫЛЫШЛЫ) МАДДӘЛӘР

## 81 НЧЕ БИТ

145. Хикмәт-е илаһия тәдбире (кору, идарә) илә хатыннарның, риҗалләрнең (ир-атларның) табигый хәлләре, табигый вазыйфалары мөхталиф (төрле) һәм мөтәфуат (аермалы) халык кылынмыш исә дә, мәдәни, иҗтимагый, сәяси, дини, әдәби хокукларның һәрберен хатыннарның һәрберенә шәригать исламия (ислам шәригате) тәмамы илә, кәмалы илә ихсан итте (рәхмәт буларак насыйп итте).

146. Хатыннар һәр хокукта ирләргә мөсәвидер (тигездер, тиңдер).

147. Бәгъзы (кайбер) хосусларда (яссылыкларда, очракларда) тәфаут (аермалык, төрлелек) кеби бер хәл бар исә дә, хокукта түгел, бәлки хозузда (язмышта), яхуд (яки) иҗтимагый вәзгыда (тормышта, хәлдә, халәттә) тәфауттыр. Мәсәлән, мирас хассәләрендә (өлешләрендә) тәфаут.

## 82 нче бит

Хозуз тәфауттыр. Хозуз инсаннарның әһәмиятләренә (булдыклылыкларына, яраклылыкларына) күрә түгел. Бәлки хәҗәтләренә күрә булыр. Шуңа күрә, мондый тәфаутларны хокук тәфаутына, әһлият тәфаутына гатеф итмәк (баглау), әлбәттә, хатадыр.

148. Ләкин хокукларга, вазыйфаларга хатыннарның әһәмиятләре мәсьәләсендә иң мөһим әсас (нигез) булмак үзрә, хатыннарның хөрмәтләре, гаилә кодсияте (изгелеге), гаилә интизамы (тәртибе, төзеклелеге), гаилә мәсләхәтләре (мәнфәгате, файдасы) игътибар кылыныр.

149. Гаилә интизамына, балаларның сәламәтлекләренә, тәрбияләренә, хатыннарның вөҗүдләренә, сыйхәтләренә (сәламәтлекләренә), хөрмәтләренә, гыйсмәтләренә (гыйффәтләренә) зарар бирә беләчәк (бирә алачак) вазыйфалардан, хезмәтләрдән һәрвакыт, һәрҗирдә хатыннар тәмам азат калып, хөрмәтләренә лаек түгел хокукларыннан да хатын һәрвакыт югары калыр.

150. Мондый тәфаутлары тәсавиларына зарар бирмәс, бәлки хөрмәтләрен тәэкид идәр (ныгытыр). Гаиләләрнең рәхәте-сәгадәте, интизамы (тәртибе, төзеклелеге) хосусларында, балаларның тәрбияләре хосусларында хатыннарның гаять бөек әһәмиятләре, гаять әһәмиятле вазыйфалары бардыр. Фараз идәек, бу вазыйфаларының беренә йә күбенә хокук сәясияләренең бере мөзәхәмәт (көндәшлек, комачау) итәчәк булыр исә, мәслихәт мөләхазасы (мәнфәгате) илә андый хокук сәясиләре тәрек кылыныр (калдырылыр, инкяр ителер). Тәрек итмәк мәхрүмият (мәхрүм булу) булмас, хөрмәт булыр, мәслихәт булыр.

151. һәлхәлдә хокукларның һәрберенә, вазыйфаларның да һәрберенә, мәсләхәтләренең дә һәрберенә ирләрнең һәрбере кеби хатыннарның һәрбере дә әһлидер (иядер).

152. Гаять авыр аналык вазыйфалары, гаять әһәмиятле гаилә идарәсе, хатыннарның хокукларына мәнгы (комачау) кеби тәлаккый кылыныр (кабул ителер, сакланыр).

153. Хатыннарның хокуклары никадәр кямил булыр исә, хөрмәтләре никадәр зиядә (күп, күбрәк) булыр исә, һәйәт иҗтимагыя (иҗтимагый строй) ул кадәр куәтле булыр.

## 83 нче бит

Әһлияте дә, хокуклары да кямил хатыннарның вәлидәлеге дә (ана, тудыручы), мәхбүбәләге дә (сөелә торган зат) зиядә (күп, күбрәк) булыр. Бәрәкәтле булыр. Хокукларның бәгъзыларыннан хатыннарның мәхрүмиятләре (мәхрүм булулары), ханә җөдарлары (йорт диварлары) арасында хатыннарның әсарәтләре (әсирлекләре) гаилә җәһәте (як, яссылык) илә файда булмас.

154. Ләкин иҗтимагый вазыйфаларына, иҗтимагый әһәмиятләренә әдәби, табигый вазыйфаларына, сәяси йә иҗтимагый хокуклары мөзәхәмәт (көндәшлек, комачау) итәчәк булыр исә, андый хокуклардан истифадәләре (файда табу) мәтлүб булмас (таләп ителмәс).

155. Гаиләләрнең низамнарына (төзелеш, система), интизамнарына (тәртипләренә, төзеклекләренә), балаларның тәрбияләренә хелал (зарар, зыян) бирмәк зарурәтенә күрә, хатыннар-кызлар мәҗбүри хезмәтләрнең һәрбереннән, әлбәттә, азат булып, дәүләт йә җәмәгать хезмәтләренең һичберенә хатын-кызларның һичбере мәҗбүрият илә сөрелмәс.

156. Фабрикаларда, заводларда, шахталарда хатын-кызларның хезмәтләрен мәдәният дөньясы да, икътисади голәмәсе дә (галимнәр) кабул идәр исә дә, тәхәммел идәр (кичерер, үткәзеп җибәрер, кабул итәр) исә дә, мондый хезмәтләргә мәҗбүрият дәһшәтләреннән, бәлки хатыннарның вөҗүдләренә (барлыгына, табигатьләренә) сыйхәтләренә (сәламәтлекләренә), гыйсмәтләренә (гыйффәтләренә) зарар бирә беләчәк хезмәтләрнең һәрбереннән үзләренең кызларын, хатыннарын азат итмәк вазыйфаларында ислам дөньясы да, Русия мөселманнарында да моннан соң, дәбәттә, иҗтиһад идәр (тырышыр, эшләр).

157. Бүгенге мәдәниятнең мондый дәһшәтле мәфсәдәләреннән (яманлыкларыннан, бозыклыкларыннан) котылмак чаралары арамак (эзләү), булмак (табу) Русия мөселманнарының да бөтен җир йөзе мөселманнарының да мөһим бер вазыйфасыдыр.

158. Мәсруфәнләр - чыгымнарын үзләре кәсеп итә белерлек кадәр хатыннарымызны-кызларымызны тәрбия итмәк, әлбәттә, зарурдыр; хатыннарның мондый бер вәзгыяттә (халәттә, хәлдә), мондый бер кодрәттә булмаклары хокукларының да, хөрриятләренең дә, хөрмәтләренең дә иң куәтле хафизыдыр (сакчысыдыр, саклаучысыдыр).

## 84 нче бит

Һәйәт иҗтимагыядә ике шәй (әйбер, нәрсә) бере җәһел (наданлык), бере зарурәт инсаннарның һәрберен, хосусән хатыннарын, сәфаләтләрнең (түбәнлекләрнең) һәрберенә сәукъ идәр (юнәтер).

Кызларның тәрбияләрендә гаять мөһим бу җәһәтендә, әлбәттә, игътибар итмәк гаилә аталарына да, өммәт рәһбәрләренә дә (җитәкчеләренә, юлбашчыларына) бүген, әлбәттә, ләземдер (тиештер).

159. Хатыннарның, кызларның хокукларына, вазыйфаларына даир бер китап, фикъһы китаплары арасында юктыр. Әхүәл (хәлләр) табигыяләренең, әхүәл фикъһияләренең хөкемнәренә даир бәяннар фикъһы китапларда, таһарәт, салят, гыйддәт кеби китапларда бар исә дә, мөҗтәһидләре дә адашырлык кадәр авырдыр. Шуңа күрә, хәлифәте ислмия, ислам шәехләре, ислам мәмләкәтләренең һәйәт фикъһишеләре мәгърифәте илә, хатыннарның, кызларның хокукларына, вазыйфаларына әхүәл табигыяләренең, әхүәл фикъһияләренең хөкемнәренә даир (кагылышлы) һәм мөҗәз (кыска) һәм асан (җиңел, кулай) һәм мәзбут (ныгытылган) бер китап тәэлиф кылынып мәктәп-мәдрәсәләрдә тәдрис кылыныр (укытылыр).

*"Иман нуры" (1998) журналыннан кыскартып алынды*

# ХӘЛӘЛМЕ? ХӘРАММЫ?

## Ашарга яраклы һәм тыелган тереклек

### 4 мәзһәб галимнәре күзлегеннән

| ИСЕМЕ | ХӘНӘФИ МӘЗҺӘБЕ БУЕНЧА | ШӘФИГЫЙ МӘЗҺӘБЕ БУЕНЧА | МӘЛИКИ МӘЗҺӘБЕ БУЕНЧА | ХӘНБӘЛИ МӘЗҺӘБЕ БУЕНЧА |
|---|---|---|---|---|
| акула | хәрам | хәләл | хәләл | хәләл |
| акчарлак | мөбах | хәләл | хәләл | хәләл |
| арыслан | хәрам | хәрам | мәкруһ | хәрам |
| ат | тәнзихан мәкруһ | хәләл | хәрам | хәләл |
| аю | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| әкәм-төкәм | хәрам | хәрам | хәләл | хәрам |
| суда үлеп, өскә калыккан балык | хәрам | хәләл | хәләл | хәләл |
| бал корты | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| бака | хәрам | хәрам | хәләл | хәрам |
| бөжан (шершень) | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| борча | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| буйвол | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| бытбылдык | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| бет | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| бөркет | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| бөҗәк | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| бүре | хәрам | хәрам | мәкруһ | хәрам |
| газель | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| гепард | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| горлица | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| дельфин | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| диңгез чучкасы | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| дуңгыз | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| дөя | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| елан | хәрам | хәрам | башы-койрыгыннан калган өлешләрен ашарга ярый | башы-койрыгыннан калган өлешләрен ашарга ярый |
| еланбалык | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| ерткыч кош (черный гриф) | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| жираф | хәләл | хәрам | хәләл | хәрам |
| ишәк | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| каз | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| карга | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| карлыгач | хәләл | хәрам | хәрам | хәрам |
| карчыга | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| камбала | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| карп | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| качыр (мул) | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| кәлтә | хәрам | хәләл | хәләл | хәләл |
| кәҗә | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| көя | хәрам | хәрам | мөбах | хәрам |
| кулан (кыргый ишәк) | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| куян | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| күгәрчен | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| күркә | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| кыр кәҗәсе | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| кырмыска | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| кыр тавыгы | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| кысла | хәрам | хәләл | хәләл | хәләл |
| кенәри | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| керпе | хәрам | хәләл | хәләл | хәрам |
| кеш | хәрам | хәләл | хәләл | хәрам |
| лачын | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| ләтчә | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| леопард | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| маймыл | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| мәче | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| мидия | мәкруһ | | | хәләл |
| саескан | хәләл | хәрам | хәрам | хәрам |
| сазан | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| сандугач | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| сапсан | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| сарык | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| саранча | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| соры челән | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| су еланы | хәрам | хәләл | хәләл | хәләл |
| сукыр тычкан | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| сусар | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| сыер | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| сыерчык | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| сыртлан (гиена) | хәрам | хәләл | хәләл | хәләл |
| тавис (павлин) | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| тавык | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| таракан | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| ташбака | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| тәвә кошы | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| тиен | хәрам | хәрам | хәләл | хәрам |
| тилгән | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| Тимсах (крокодил) | хәрам | хәрам | хәләл | хәрам |
| торна | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| төлке | хәрам | хәләл | мөбах | хәрам |
| тургай | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| тутый кош | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| тычкан | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| урман үрдәге | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| үрмәкүч | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| фил | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| чаян | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| чикерткә | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| чуллык (бекас) | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| чүл бүресе (шакал) | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| чебен | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| чыпчык | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| эт | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| эш үгезе (вол) | хәләл | хәләл | хәләл | хәләл |
| юлбарыс | хәрам | хәрам | мәкруһ | хәрам |
| ябалак | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |
| ярканат | хәрам | хәрам | мәкруһ | хәрам |
| һөдһөд (удод) | хәрам | хәрам | хәрам | хәрам |

---

*Мәкруһ – шәригатьтә хупланмаган гамәл, ләкин аның өчен җәза бирелми.
*Мәкруһ тәнзихан – шәригатьтә хупланмаган гамәл, ул мөбахка якын.
*Мөбах – савабы да, гөнаһы да булмаган рөхсәт ителгән гамәл.

## HUZURSHOP.RU - "ХУЗУР" НӘШРИЯТЫНЫҢ ИНТЕРНЕТТАГЫ КИБЕТЕ

***Хәзер "Хузур" нәшрият йорты китапларын интернеттан да сатып алырга мөмкин. Нәшриятның интернет кибете - Huzurshop.ru барлыкка килде. Он-лайн кибеттә Коръән һәм тәфсирләр, татар дин галимнәре хезмәтләре, дини китаплар, "Шура" альманахы, гарәп теле дәреслекләре бар.***




## "Азан" радиосы "Кстати говоря" тапшыруын яңартылган форматта тыңларга чакыра

Хәзер **"КСТАТИ ГОВОРЯ"** тапшыруын ике телдә: русча һәм татарча ишетергә була. Биредә һәр атнаның дүшәмбе көннәрендә туры эфирда ислам дөньясында көн кадагына сугучы мәсәләләрне уртага салып сөйләшәләр, бергәләп аларны чишү юлларын эзлиләр. Студия кунаклары танылган дин белгечләре, республикабызда ислам динен үстерүгә хезмәт куючы дин әһелләре.

Кунаклар белән әңгәмәне **10 сәгать 30 минутта** Алмаз Әхмәтҗанов рус теленда алып бара. **11 сәгаттә** исә Эльвира Мутавалова **"КУНАКХАНӘ"** тапшыруында студия кунаклары белән аралашуны татар телендә дәвам итә.




## ДӘРЕСЛӘРГӘ КИЛЕГЕЗ

Татарстан мөфтие **Камил хәзрәт Сәмигуллин**нең "Тәфсир" буенча дәресләре кабат башланды. Коръәнне тәфсир кылу һәм тәрҗемә итүгә кагылышлы дәресләр Казанның Тынычлык мәчетендә үткәрелә. Алар һәр атнаның җомгасында ястү намазыннан соң уздырыла. Теләгән һәркем килә һәм дини гыйлем туплый, Изге китап белән таныша ала. Шулай ук дәрес темасы буенча мөфтигә сораулар да бирергә мөмкин.

***

Гаилә мәчетендә мөфти урынбасары, мәчетнең имам-хатыйбы **Рөстәм хәзрәт Хәйруллин**ның гаилә дәресләре дәвам итә. Белгәнебезчә, бу дәресләр узган ел башланган иде. Аерым алганда, хәзрәт диндә бала тәрбияләү, гаилә мәсьәләләрен чишү юллары кебек темаларны кузгата. Шулай ук гаиләне саклап калу, аерылышудан качу кебек четерекле мәсьәләләр турында сөйләшү алып бара. Дәресләр

## НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Таң беленә башлый | Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә Намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы | Кыбла |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.03.2015 | 04:33 | 05:05 | 06:35 | 11:55 | 15:19 | 17:17 | 18:58 | 12:51 |
| 02.03.2015 | 04:30 | 05:03 | 06:33 | 11:55 | 15:21 | 17:19 | 19:00 | 12:50 |
| 03.03.2015 | 04:27 | 05:00 | 06:30 | 11:55 | 15:23 | 17:21 | 19:02 | 12:50 |
| 04.03.2015 | 04:25 | 04:58 | 06:28 | 11:55 | 15:25 | 17:23 | 19:04 | 12:49 |
| 05.03.2015 | 04:22 | 04:55 | 06:25 | 11:55 | 15:27 | 17:25 | 19:06 | 12:49 |
| 06.03.2015 | 04:20 | 04:53 | 06:23 | 11:54 | 15:28 | 17:27 | 19:08 | 12:48 |
| 07.03.2015 | 04:17 | 04:50 | 06:20 | 11:54 | 15:30 | 17:29 | 19:11 | 12:48 |
| 08.03.2015 | 04:14 | 04:48 | 06:18 | 11:54 | 15:32 | 17:31 | 19:13 | 12:47 |
| 09.03.2015 | 04:12 | 04:45 | 06:15 | 11:54 | 15:34 | 17:33 | 19:15 | 12:47 |
| 10.03.2015 | 04:09 | 04:42 | 06:12 | 11:53 | 15:35 | 17:35 | 19:17 | 12:46 |
| 11.03.2015 | 04:06 | 04:40 | 06:10 | 11:53 | 15:37 | 17:37 | 19:19 | 12:46 |
| 12.03.2015 | 04:03 | 04:37 | 06:07 | 11:53 | 15:39 | 17:39 | 19:21 | 12:45 |
| 13.03.2015 | 04:01 | 04:35 | 06:05 | 11:53 | 15:41 | 17:42 | 19:24 | 12:45 |
| 14.03.2015 | 03:58 | 04:32 | 06:02 | 11:52 | 15:42 | 17:44 | 19:26 | 12:44 |
| 15.03.2015 | 03:55 | 04:30 | 06:00 | 11:52 | 15:44 | 17:46 | 19:28 | 12:44 |
| 16.03.2015 | 03:52 | 04:27 | 05:57 | 11:52 | 15:46 | 17:48 | 19:30 | 12:43 |
| 17.03.2015 | 03:49 | 04:24 | 05:54 | 11:51 | 15:47 | 17:50 | 19:33 | 12:43 |
| 18.03.2015 | 03:46 | 04:22 | 05:52 | 11:51 | 15:49 | 17:52 | 19:35 | 12:42 |
| 19.03.2015 | 03:43 | 04:19 | 05:49 | 11:51 | 15:51 | 17:54 | 19:37 | 12:42 |
| 20.03.2015 | 03:40 | 04:17 | 05:47 | 11:51 | 15:52 | 17:56 | 19:39 | 12:41 |
| 21.03.2015 | 03:37 | 04:14 | 05:44 | 11:50 | 15:54 | 17:58 | 19:42 | 12:41 |
| 22.03.2015 | 03:34 | 04:11 | 05:41 | 11:50 | 15:55 | 18:00 | 19:44 | 12:40 |
| 23.03.2015 | 03:31 | 04:09 | 05:39 | 11:50 | 15:57 | 18:02 | 19:46 | 12:40 |
| 24.03.2015 | 03:28 | 04:06 | 05:36 | 11:49 | 15:59 | 18:04 | 19:49 | 12:39 |
| 25.03.2015 | 03:24 | 04:03 | 05:33 | 11:49 | 16:00 | 18:06 | 19:51 | 12:39 |
| 26.03.2015 | 03:21 | 04:01 | 05:31 | 11:49 | 16:02 | 18:08 | 19:54 | 12:38 |
| 27.03.2015 | 03:18 | 03:58 | 05:28 | 11:48 | 16:03 | 18:10 | 19:56 | 12:38 |
| 28.03.2015 | 03:15 | 03:56 | 05:26 | 11:48 | 16:05 | 18:12 | 19:59 | 12:37 |
| 29.03.2015 | 03:11 | 03:53 | 05:23 | 11:48 | 16:06 | 18:14 | 20:01 | 12:36 |
| 30.03.2015 | 03:08 | 03:50 | 05:20 | 11:48 | 16:08 | 18:16 | 20:04 | 12:36 |
| 31.03.2015 | 03:05 | 03:48 | 05:18 | 11:47 | 16:09 | 18:18 | 20:06 | 12:35 |

**По вопросам рекламы обращаться по телефону (843) 253-60-52**

## "Иманның татлылыгы. Сахих Бохари (хәдисләр)" китабы дөнья күрде




ТР МДНнең **"ХУЗУР"** нәшрият йорты **"Иманның татлылыгы. Сахих Бохари (хәдисләр)"** китабын нәшер итте. Әл-Бохари ислам дөньясында киң танылган хәдисләр җыентыгы - күптомлы "Әл Җамигъ әс-Сахих" ("Ышанычлы хәдисләр җыелмасы") китабы авторы, исламият галиме. Әлеге җыентыкны төзегәндә әл-Бохари 1000 дин галиме белән киңәшә, 600 мең хәдисне тикшерә, 200 мең хәдис язып ала, шулар арасыннан дөреслеккә туры килә дип исәпләгән 7397 хәдисне сайлап ала. Шул заманда ук "Әс-Сахих" фикһ өлкәсендә мөһим кулланма буларак таныла. 1917 елга кадәр әл-Бохари туплаган хәдисләр Казанда берничә тапкыр басыла. 1990 еллардан соң хәдисләр җыентыгының татар һәм рус телләрендәге берничә кыскартылган нөсхәсе нәшер ителде.

Китапны нәшрият кибетләреннән алырга була. Нәшрият йортының рәсми сайты ***huzur.ru***, электрон почта: ***huzur.inform@mail.ru***




ДИН вә МӘГЫЙШӘТ
Февраль саны, № 2 (235)

**Мөхәррир:** Нәүбәһар Кәбирова
**Дизайнер:** Гүзәл Миңнуллина
**Корректор:** Айгөл Крохина
Газета логотибы **хәттат** Рамил Насыйбуллов тарафыннан эшләнде

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** *420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27/*
**Электрон адрес:** *naubahar67@list.ru.*
**Телефон:** *+7 950 326 38 36*

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе* ***Камил СӘМИГУЛЛИН****;*
*"Хузур" нәшрият йорты директоры* ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН****;*
*ТҖМДНнең дәгъват бүлеге җитәкчесе* ***Нияз САБИРОВ****;*
*Татарстанның баш казые* ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ****;*
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе* ***Габдулла ӘДҺӘМОВ****.*

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** *Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).*
**Нәшир:** *"Хузур" нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в)*

*Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.*
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" ААҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды *(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2).*
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9052**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **25 нче февраль** көнне **18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **18.00 сәгатьтә.**